ЯХЪЯ ТӘГЪБИР иткән

инҗил

## Сүз Кеше булды

1:1 Иң башта Сүз булган, Сүз Аллада булган, һәм Сүз Алла булган. 2 Сүз иң
башта ук Аллада булган. 3 Бар нәрсә Сүз аша яратылган, һәм яратылган һәр
нәрсә Аннан башка яратылмаган. 4 Аңарда тормыш булган, һәм шул тормыш
кешеләргә яктылык биргән. 5 Яктылык караңгылыкта яктыра, караңгылык исә аны
сүндерә алмаган. 6 Алла тарафыннан җибәрелгән Яхъя исемле бер кеше бар
иде. 7 Яхъя шаһәдәт бирү өчен кидце. Ул, барысы да иман китерсеннәр дип,
Яктылык хакында шаһәдәт бирергә килде. 8 Ул үзе Яктылык түтел, ләкин Яктылык
хакында шаһәдәт бирү өчен җибәрелгән иде. 9 Чын Яктылык - дөньяга килүче һәр
кешене яктыртучы Яктылык иде. 10 Ул дөньяда булды, ләкин дөнья, Аның аша
яратылган булуга карамастан, Аны танымады. 11 Ул үз кешеләре янына килде,
әмма үзенекеләр Аны кабул итмәделәр. 12 Ә Үзен кабул итеп, Аның исеменә
иман китерүчеләргә, Ул Алла балалары булырга хокук бирде. 13 Алар каннан да,
тән нәфесеннән дә, ир нәфесеннән дә түгел, бәлки Алладан тудылар. 14 Сүз
Кеше булды, мәрхәмәт һәм хакыйкать белән тулы булып, безнең арабызда яшәде,
һәм без Аның данын, Атаның бердәнбер Улына биргән данын күрдек. 15 Яхъя
пәйгамбәр, Аның хакында шаһәдәт биреп: - «Миннән соңрак Килүче миннән алга
чыкты, чөнки Ул миннән элек бар иде», дип сөйләгәнем менә Шул инде, - дип
кычкырып әйтте. 16 Аның тулылыгыннан без һәммәбез мәрхәмәт өстенә мәрхәмәт
алдык, 17 чөнки канун Муса аркылы бирелде, мәрхәмәт һәм хакыйкать исә, Гайсә
Мәсих аша килделәр. 18 Алланы беркем, беркайчан күрмәде. Аны Атаның
күңеленә иң якын булган бердәнбер Улы ачып бирде.

## Яхъя пәйгамбәрнең шаһәдәте

19 Иерусалим яһүдләре руханиларны һәм левилеләрне Яхъя пәйгамбәрдән: «Син
кем?» - дип сорар өчен җибәргәч, ул шаһәдәт биреп, 20 һич тә яшермичә: - Мин
Мәсих түгел, - дип икърар итте. 21-22 Алар аннан: - Кем соң син, Ильясмы? - дип
сорадылар. - Юк. - Вәгъдә ителгән пәйгамбәрме? - Юк, - диде Яхъя. - Алайса, кем
соң син? Безне монда җибәрүчеләргә җавап бирү өчен үзең хакыңда безгә син
нәрсә әйтерсең? 23 Яхъя аларга: - Мин, Исай пәйгамбәр әйткән кебек: «Ходайга
юлны турайтыгыз», - дип чүлдә кычкыручы аваз, - диде. 24 Җибәрелгәннәр
фарисейләрдән иделәр. 25 Алар Яхъядан: - Син Мәсих тә, Ильяс та, вәгъдә
ителгән пәйгамбәр дә булмагач, ни өчен соң халыкны суга чумдырасың? - дип
сорадылар. 26 Яхъя аларга: - Мин суга чумдырам, әмма арагызда сез белмәгән
Берәү тора. 27 Миннән соңрак Килүче нәкъ менә Шул инде, ә мин Аның
башмагының каешын чишәргә дә лаеклы түгелмен, - дип җавап бирде. 28 Бу

вакыйгалар Яхъя пәйгамбәр чумдыра торган урында - Иордан елгасы
аръягындагы Бетанида булды. 29 Икенче көнне Яхъя пәйгамбәр, каршына килүче
Гайсәне күреп, әйтте: - Менә дөньяның гөнаһын алучы Алла Бәрәне. 30 «Миннән
соңрак килүче бер Зат миннән алга чыкты, чөнки Ул миннән элек бар иде», - дип
сөйләгәнем Ул - Үзе. 31 Мин Аны белми идем, ләкин, Аны Исраил халкы белсен
дип, суга чумдырырга килдем. 32 Яхъя пәйгамбәр шаһәдәт биреп, естәп әйтте: -
Мин күгәрчен рәвешендә күктән Рух иңүен һәм Аның өстендә калуын күрдем. 33
Мин Аны танымас идем, әмма мине суга чумдыру өчен Җибәрүче: «Кем өстенә
Рух иңүен һәм Аның өстендә калуын күрсәң, Изге Рухка чумдыручы Шул булыр», -
диде. 34 Мин моны күрдем һәм шаһәдәт бирәм: Ул - Алла Улы.

## Гайсәнең беренче шәкертләре

35 Икенче көнне Яхъя пәйгамбәр шәкертләренең икесе белән шул ук урында
торганда, 36 узып баручы Гайсәне күреп: - Карагыз, Алла Бәрәне, - диде. 37 Ике
шәкерт, аның бу сүзләрен ишеткәч, Гайсә артыннан киттеләр. 38 Гайсә исә,
артына әйләнеп карады һәм, аларның арттан килүен күреп: - Сезгә нәрсә кирәк? -
диде. Алар Аннан: - Рабби, Син кайда яшисең? - дип сорадылар. (Рабби - яһүд
телендә Остаз дигән мәгънәдә.) 39 Гайсә аларга: - Эйдәгез Минем белән, үзегез
күрерсез, - диде. Ул вакытта унынчы сәгать чамасы иде. Алар, Аның белән барып,
Гайсә кайда яшәгәнен күрделәр һәм ул көнне Аның янында калдылар. 40 Яхъя
пәйгамбәрнең Гайсә турындагы сүзләрен ишетеп, Аның артыннан киткән икәүнең
берсе Симон Питернең энесе Эндри иде. 41 Ул, иң элек абыйсы Симонны табып,
аңа: - Без Мәсихне очраттык, - диде, һәм Симонны Гайсә янына алып килде.
(Мәсих - «Май сөртелгән Зат» дигән мәгънәдә.) 42 Гайсә исә, Симонга карап: -
Син, Юныс улы Симон: син, Кифа дип аталырсың, - диде. (Кифа һәм Питер дигән
исемнәр «кыя» дигән мәгънәдә.) 43-44 Икенче көнне Гайсә, Галилеягә барырга
уйлагач, Эндри белән Питер кебек үк Бетсайд шәһәреннән булган Филипны
очратып, аңа: - Минем артымнан бар, - диде. 45 Филип, Натанаилне табып, аңа: -
Без Муса канунда язган Насаралы Йосыф улы Гайсәне очраттык. Аның хакында
пәйгамбәрләр дә язганнар, - диде. 46 Ләкин Натанаил аңа: - Насарадан нинди дә
булса яхшы нәрсә чыгармы икән? - дип җавап бирде. - Барыйк, үзең күрерсең, -
диде Филип. 47 Гайсә, Үзенә таба якынлашкан Натанаилне күреп, аның хакында: -
Менә чын исраилле, ул һич мәкерле түгел, - диде. 48 Натанаил Аннан: - Син мине
каян беләсең? - дип сорады. - Мин сине, Филип сине чакырганчыук, инҗир агачы
төбендә күрдем, - дип җавап бирде Гайсә. 49 Натанаил Аңа: - Остаз! Син - Алла
Улы! Син - Исраил Патшасы! - диде. 50 Гайсә аңа: - Син Минем: «Мин сине инҗир
агачы төбендә күрдем», - дигәнемә күрә генә иман китерәсеңме? Моннан да
зуррак нәрсәләр күрерсең әле, - дип җавап бирде һәм, дәвам итеп, - 51 сезгә чын
дөресен әйтәм: күкләр ачылуын һәм Алла фәрештәләренең Адәм Улы янына
күтәрелеп иңүләрен күрерсез, - диде.

## Гайсәнең суны шәрабка әйләндерүе

2:1 Өченче көнне Галилея өлкэсенең Кана шэһэрендэ туй булды. Туйга Гайсәнең
анасы да кидце. 2 Гайсә дә Үзенең шэкертләре белән шул туйта чакырылган иде.
3 Шәраб җитмәгәч, Гайсәнең анасы Аңа: - Аларның шәраблары беткэн, - диде. 4
Гайсә Аңа: - Син ни өчен моны Миңа эйтәсең? Минем әле вакытым килеп
җитмэде, - диде. 5 Анасы хезмәтчеләргә: - Ул сезгә нәрсә эйтсэ, шуны эшлэгез, -
диде. 6 Анда, яһүдләрнең дини йоласы буенча, пакьләнү өчен куелган ике яки өч
үлчэү су сыйдырышлы алты таш чүлмәк бар иде. 7 Гайсә хезмәтчеләргә: -
Чүлмәкләрне су белән тутырыгыз, - дип эйткәч, алар чүлмәкләрне мөлдерәмә
итеп тутырдылар. 8 Шуннан соң Гайсә аларга: - Инде чумырып алыгыз да, туй
башлыгына илтеп бирегез, - диде. Алар илтеп бирделәр. 9 Туй башлыгы
шәрабның кайдан икәнен белми иде. Аны суны чумырып алган хезмәтчеләр генэ
белә иде. Туй башлыгы, шэрабка әйләнгән суны татып карагач, кияүне үз янына
чакырып алып: 10 - Башта һәркем яхшы шәраб бирэ, ә инде җитәрлек эчелгәч,
начаррагын китерә; ә син яхшы шәрабны иң соңга кадцыргансың. 11 Шулай итеп,
Гайсэ, Галилеянең Кана шэһэрендә могҗизалы галәмәтләрен башлап җибәреп,
Үзенең данын күрсәтте, һәм шәкертлэре Аңа иман китерделәр. 12 Шуннан соң
Гайсә, анасы, энеләре һәм шәкертлэре белән бергә Капарнаум шәһәренә килеп,
анда берничэ көнгә калды.

## Гайсэнең Алла Йортына мэхэббэте

13 Яһүдләрнең Коткарылу бәйрәме якынлашкач, Гайсә Иерусалимга кидце. 14 Ул
андагы Алла Йортында үгез, сарык, күгәрчен сатучыларны һәм акча алмаштырып
утыручыларны күргэч, 15 баудан чыбыркы үреп, барысын да - сарыкларны да,
үгезләрне дә Алла Йортыннан куып чыгарды. Ул, акча алмашты-ручыларның
өстәлләрен аударып ташлап, акчаларын чәчеп җибэрде. 16 Күгэрчен
сатучыларга: - Боларны моннан алыгыз! Минем Атамның йортын базарга
эйлэндермэгез! - диде. 17 Аның шәкертләре: «Мине Синең йортыңа булган
мәхэббәт газаплый», - дип язылган сүзләрне исләренэ төшерделэр. |Х Шуннан,
яһүдлэр Гайсэдэн: - Син, болай эшләргә вәкалэтең барлыгын, безгә нинди
галәмәт белэн исбат итә аласың? - дип сорадылар. 19 Гайсә аларга: - Бу Алла
Йортын җимереп ташлагыз һэм Мин аны өч көндә торгызачакмын, - диде. 20
Яһүдләр Аңа әйттелэр: - Бу Алла Йорты кырык алты ел төзедде, Син аны өч
кендә генэ торгыза алырсыңмы? 21 Эмма Гайсә, Алла Йорты дип, Үзенең тәне
хакында эйткэн иде. 22 Гайсә үлгән җиреннән терелеп торгач, шәкертләре Аның
бу турыда әйткәнен исләренэ тешерделәр һэм, Изге Язмага да, Гайсэ эйткән
сүзлэргэ дэ ышандылар. 23 Коткарылу бәйрәме көннэрендә Аның Иерусалимда
күрсәткән могҗизалы галәмәтләрен күреп, күплэр Гайсә исеменә иман
китерделэр. 24-25 Эмма Гайсә, бөтен кешелэрне Үзе белгэнгә күрә, кешеләр
турында кемнең дә булса сөйләп бирүенә ихтыяҗы юк иде, чөнки кешеләрнең
күңеллэрендә нәрсә булганын Ул белде һэм шуңа күрэ аларга ышанмады.

## Гайсэ һэм Никэдим

3:1 Фарисейләр арасында яһүд башлыкларының Никәдим атлысы 2 тонлә Гайсә
янына килеп, Аңа: - Остаз! Без Синең Алладан килгән Остаз икәнеңне беләбез;
чөнки, Алла аның белән булмаса, Син күрсәткән могҗизалы галәмәтләрне беркем
дә эшли алмас иде, - диде. 3 Гайсә аңа: - Сиңа чын дересен әйтәм: кем дә кем
яңадан тумаса, Алла Патшалыгын күрә алмас, - дип әйтте. 4 Никәдим Аннан: -
Кеше картайгач ничек итеп яңадан туа алсын? Ул анасы карынына икенче тапкыр
кереп туа алырмы? - дип сорады. 5 Гайсә җавабында аңа әйтте: - Сиңа чын
дөресен әйтәм: кем дә кем судан һәм Рухтан тумаса, Алла Патшалыгына керә
алмас. 6 Тәннән туган - үзе тән, Рух ган туган - үзе рух. 7 Минем сиңа: «Сез
яңадан туарга тиешсез», дип әйтүемә гаҗәпләнмә. 8 Җил кайда теләсә, шунда
исә, аның тавышын ишетәсең, ләкин кайдан килеп кая китүен белмисең: Рухтан
туган һәркем белән нәкъ менә шулай була. 9 Никәдим Аннан: - Ничек алай була
алсын? - дип сорады. 10 - Син Исраил мөгаллиме була торып шуны белмисеңме?
- диде аңа Гайсә. 11 - Сиңа чын дөресен әйтәм: без нәрсә белсәк, шуны сөйлибез;
нәрсә күрсәк, шуңа шаһәдәт бирәбез; ә сез безнең шаһәдәтебезне кабул итмисез.
12 Сез җирдәге хәлләр турында сөйләгәнгә ышанмыйсыз икән, күктәгеләре
хакында сөйләсәм, ничек ышанырсыз? 13 Күктән иңгән Адәм Улыннан башка
берәүнең дә күккә күтәрелгәне юк. 14-15 Аңа иман китерүче һәр кеше мәңгелек
тормыш алсын өчен, Муса чүдцә еланны күтәргән кебек, Адәм Улы да
күтәрелергә тиеш. 16 Ченки Алла дөньяны шулкадәр яратты ки, Улына иман
китерүче һәркем һәлак булмасын, бәлки мәңгелек тормыш алсын өчен, Үзенең
бердәнбер Улын бирде. 17 Алла Үзенең Улын деньяны хөкем итү өчен түгел,
бәлки Аның аша дөнья котылсын дип, дөньяга җибәрде. 18 Аңа иман китерүчегә
хөкем юк, ә иман китермәүче хөкем ителде инде, чөнки ул Алланың бердәнбер
Улы исеменә иман китермәде. 19 Хөкем исә, шуннан гыйбарәт: дөньяга яктылык
килде, әмма кешеләр, эшләре яман булганга күрә, яктылык урынына
караңгылыкны яраттылар. 20 Явызлык эшләүче һәркем яктылыкка нәфрәт итә
һәм, үзенең эшләре ачылмасын дип, яктылыкка килми. 21 Ә дөреслек буенча эш
итүче, эшләренең Алла аркылы эшләнгәнлеге ачык күренсен өчен, яктылыкка
килә.

## Яхъя пэйгамбәрнең Гайсә турындагы шаһәдәте

22 Шуннан соң Гайсә, шәкертләре белән Яһүдия җиренә килеп, алар белән бергә
шунда калып халыкны суга чумдырды. 23 Яхъя да Салим янындагы күп сулы
Айнонда шунда килгән кешеләрне суга чумдыра иде. 24 Ул вакытта эле Яхъя
төрмәгә утыртылмаган була. 25 Яхъя пэйгамбәрнең шәкертләре белән бер яһүд
кешесе арасында пакьләнү турында бәхәс чыккач, 26 алар Яхъя пәйгамбәр янына
килеп: - Остаз! Менә Иорданның аръягында синең белән булган һәм син Аның
турында шаһәдәт биргән Кеше халыкны суга чумдыра, һәм барысы да Аның
янына баралар, - дип әйттеләр. 27 Яхъя пәйгамбәр җавап итеп әйтте: - Күктән
бирелмәгән булса, кеше үзенә бернәрсә дә кабул итә алмый. 28 Сез минем: «Мин
Мәсих түгел, әмма мин Аның алдыннан җибәрелдем», - дип әйткәнемне ишетүче

шаһитлар. 29 Кияү кешенең кәләше була, ә кияүнең янында тыңлап торучы
дусты, аның тавышын ишетеп, шатланып куана. Минем куанычым да шулай тулы.
30 Ул үсәргә, мин кечерәергә тиеш. 31 Югарыдан Килүче һәркемнән өстенрәк; ә
җирдән булган, җирнеке булып, җирдәгечә сөйләр. Күктән Килүче һәркемнән
өстендер: 32 Ул Үзе күргәннәре һәм ишеткәннәре турында шаһәдәт бирә, әмма
Аның шаһәдәтен берәү дә кабул итми. 33 Аның шаһәдәтен кабул итүче Алланың
хаклыгына инануын раслап, мөһер суккан була. 34 Алла җибәргән Кеше Алла
сүзләрен сөйләр, чөнки Алла Рухны үлчәп бирми. 35 Ата Үзенең Улын ярата һәм
бар нәрсәне Аның кулына биргән. 36 Улына иман китерүченең мәңгелек тормышы
бар, ә Улына иман китермәүче тормыш күрмәячәк, бәлки аның естендә Алланың
ачуы торачак.

## Гайсә һәм Самария хатыны

4:1 Фарисейләр Гайсәнең Яхъя пәйгамбәргә караганда күбрәк шәкертләр җыюы
һәм аларны суга чумдыруы турында ишеттеләр, 2 әмма, Гайсә Үзе түгел, бәлки
Аның шәкертләре суга чумдыра иделәр. 3 Гайсә, бу турыда белгәннән соң,
Яһүдияне калдырып, тагын Галилеягә китте. 4 Аңа Самария аша үтәргә туры
килде. 5 Ул Якуп үзенең улы Йосыфка биргән җир биләмәгенә якын урнашкан
Самариянең Сихар дигән шәһәренә килде. 6 Анда Якуп коесы бар иде. Юлда
арыган Гайсә шул кое янына килеп утырды. Алтынчы сәгать чамасы иде. 7-8
Шәкертләре ризык сатып алу өчен шәһәргә киткәч, су алырга дип, бер Самария
хатыны килде. Гайсә аңа: - Миңа эчәргә бирче, - диде. Самария хатыны Аңа: 9 -
Ничек итеп Син, яһүд була торып, миннән, Самария хатыныннан, эчәргә
сорыйсың? - диде. Ул бу сүзләрне яһүдләр самариялеләр белән аралашмаганга
күрә әйтте. 10 Гайсә аңа җавап биреп: - Алланың бүләген белсәң һәм синнән:
«Миңа эчәргә бирче», - дип сораучының кем икәнлеген белсәң, син үзең Аннан
сорар идең, һәм Ул сиңа тереклек суы бирер иде, - диде. 11 Хатын Аңа әйтте: -
Эфәндем! Синең чумырып алырга бернәрсәң дә юк, ә кое тирән. Син ул тереклек
суын кайдан алырсың икән? 12 Бу коены безгә Якуп атабыз биргән: үзе дә,
балалары да, малтуарлары да шушы коедан эчкәннәр. Син Якуп атабыздан да
бөегрәкме әллә? 13 Гайсә аңа җавап бирде: - Бу суны эчкән һәркем янә сусар, 14
ә кем дә кем Мин бирәчәк суны эчсә, һичкайчан сусамас. Мин биргән су аңарда
мәңгелек тормышка ага торган чишмәгә әвереләчәк. 15 Хатын Аңа әйтте: -
Эфәндем! Миңа шул суны бирче, аннан мин сусамас идем һәм, су алыр өчен,
монда килеп йөрмәс идем. 16 Гайсә аңа: - Бар, иреңне чакырып кил, - диде. 17
Хатын Аңа: - Минем ирем юк, - дип җавап бирде. Гайсә аңа: - Ирем юк, дип син
дөресен әйттең, 18 чөнки синең биш ирең булды, ә инде хәзергесе сиңа ир түгел.
Син моны дөрес әйттең, - диде. 19 Хатын Аңа әйтте: - Әфәндем! Күрәм, Син
пәйгамбәрсең, ахры. 20 Безнең ата-бабаларыбыз Аллага бу тауда табынганнар, ә
сез кешеләр табына торган урын Иерусалимда булырга тиеш, дисез. 21 Гайсә аңа
әйтте: - Ханым, ышан сүземә, вакыт җитә: Атага табынуыгыз бу тауда да,
Иерусалимда да булмаячак. 22 Сез кемгә табынуыгызны белмисез, ә без кемгә

табынуыбызны беләбез, чөнки котылу яһүдләрдән килә. 23 Эмма вакыт килә, һәм
килеп тә җитте инде, ул чакта чын күңелдән табынучылар Атага рухта һәм
хакыйкатьтэ табынырлар, чөнки Ата шундый табынучыларны эзли. 24 Алла - Рух
Ул, һәм Аңа табынучылар рухта һәм хакыйкатьтә табынырга тиешләр. 25 Хатын
Аңа: - Мэсихнең (Май сөртелгән Затның) киләчәген беләм. Ул килгәч, безгә
бөтенесен игълан итәр, - диде. 26 Гайсә аңа: - Синең белән сөйләшүче Мин - ул
Үзе, - диде. 27 Шул вакыт әйләнеп кайткан шәкертләре, Аның хатын белән
сөйләшүен күреп, гаҗәпләнделәр, эмма берсе дә: «Син аңардан нәрсә
сорыйсың?» - дип яки: «Бу хатын белән нәрсә турында сөйләшәсең?» - дип
сорамады. 28 Хатын, су чүлмәген калдырып, шәһәргә китте һәм андагы
кешеләргә: 29 - Барып карагыз әле, минем кылган бөтен эшләремне сөйләп
биргән Кешене күрерсез; Ул Мәсих түгелме икән? - диде. 30 һәм кешеләр,
шэһәрдән чыгып, Гайсэ янына киттелэр. 31 Ул арада шәкертләре Аны: - Остаз!
Ашап ал инде, - дип кыстарга керештелэр. 32 Гайсә аларга: Минем сез белми
торган ризыгым бар, - диде. 33 Шәкертләре үзара: - Эллә Аңа берэрсе ашарга
китердеме икән? - диештелэр. 34 Гайсэ аларга эйтте: - Минем ризыгым - Мине
Җибәрүченең ихтыярын үтәү һәм Аның эшен төгәлләү. 35 Сез: «Тагын дүрт айдан
урак өсте җитәчәк», - дисез түгелме? Ә Мин сезгә әйтәм: әйбәтләп карагыз,
игеннәр агарып уракка өлгергән инде. 36 Уручы эш хакы ала һәм мәңгелек
тормыш өчен уңыш җыя. Шуңа күрә, чәчүче дә, уручы да бергә куаналар. 37
Шулай итеп, бу очракка: «Берсе чәчә, ә икенчесе ура», - дигән әйтем туры килә.
38 Мин сезне үзегез эшләмәгәнне урырга җибәрдем, анда башкалар эшләде, ә
сез аларның хезмәт уңышын җыясыз. 39 - Ул минем бөтен кылган эшләремне
сөйләп бирде, - дип шаһәдәт иткән хатынның сүзен ишеткәч, әлеге шәһәрдәге
самариялеләрнең күбесе Аңа иман китерделәр. 40 Шунлыктан, самариялеләр,
Аның янына килеп, Аңардан үзләренең янында калуын үтенеп сорагач, Ул анда
ике көнгә калды. 41 Аның Үзенең сәйләгәнен ишетеп, тагын да күбрәк кешеләр
Аңа иман китерделәр, 42 э теге хатынга исэ: - Без инде синең сүзләреңне ишетеп
түгел, бэлки, үзебез Аның сүзләрен ишетеп һәм Аның чыннан да дөньяны
Коткаручы Мэсих икәнлеген белеп, Аңа иман китерэбез, - диделәр.

## Гайсэ сарай эһелепең улын савыктыра

43 Ике көн үткәч, Гайсә бу шэһәрдән Галилеягә китте. 44 «Пэйгамбәрнең үз
илендә ихтирамы юк», - дип Гайсэ Үзе үк шаһэдэт биргән иде. 45 Галилеялеләр
бэйрэмдә катнашкан булганга күрә, Иерусалимда бэйрэм көннәрендә Гайсә
эшләгән барлык эшләрне күргәнлектән, Ул Галилеягэ килгәч, Аны бик телэп
кабул иттелэр. 46 Шуннан соң, Гайсэ теге чакта суны шэрабка әйләндергән
урынга - Галилеянең Кана шәһәренә яңадан килде. Капарнаумда бер сарай әһеле
һәм аның авыру улы бар иде. 47 Сарай әһеле, Гайсэнең Яһүдиядән Галилеягэ
килгэнен ишетеп, Аның янына китте. Аның килүен һәм үлем алдында яткан улын
савыктыруын ялварып сорады. 48 Гайсә аңа: - Илаһи билгелэр һәм могҗизалар
күрмәсәгез, сез бит иман китермәячәксез, - диде. 49 Сарай әһеле Аңа: -

Эфэндем! Балам үлгэнче килэ күр инде, - диде. 50 Гайсэ аңа: - Бар, өеңэ кайт, синең улың савыкты, - диде. Сарай эһеле, Гайсэнең сүзенә ышанып, кайтып китте. 51 Кайтышлый, хезмэтчелэре очрап: - Улың савыкты, - диделэр. 52 - Аңа кайсы сэгатьтэ хэл керде? - дигэн соравына, алар: - Кичә җиденче сәгатьтә бизгәк аннан китте, - дип җавап бирделэр. 53 Әти кеше, Гайсэнең «Улың савыкты» дигэн сүзләренең нэкъ шул сэгатькэ туры килгәнен аңлагач, ул үзе дэ, аның йортындагыларның барысы да Гайсэгэ иман китерделэр. 54 Бу Гайсәнең Яһүдиядэн Галилеягэ килгэч күрсэткэн икенче могҗизалы галәмэте иде.

## Буа буенда еавыктыру

5:1 Шуннан соң, Гайсэ яһүдлэрнең Иерусалимда булган бер бэйрэменэ килде. 2 Иерусалимда, Сарык Капкасы янында яһүдчә Бетезда дип аталган буа баганалардан горган ябык өсле биш корылма белэн уратып алынган иде. 3 Анда бик күп авырулар: сукырлар, аксаклар һэм паралич суккан кешелэр [су кузгалуын көтеп] яталар иде. 4 [Чөнки вакыт-вакыт Ходайның бер фәрештэсе, буага төшеп, суны болгата һэм, су болгану белән, аңа беренче булып кергэн кеше геләсэ нинди авырудан да савыга икэн.] 5 Шунда утыз сигез ел буе авыручы бер кеше бар иде. 6 Гайсә, ул кешене күреп һэм аның озак вакыт ятуын белеп, аннан: - Савыгасың килэме? - дип сорады. 7 Авыру Аңа: - Эйе, Әфэндем. Лэкин су болганган вакытта мине буага төшерер кеше юк, мин анда барып җиткэнче, башка берәү инде төшеп өлгергэн була, - дип җавап бирде. 8 Гайсә аңа: - Тор, ятагыңны ал да йөр, - диде. 9 Кеше шунда ук торелде һэм ятагын алып йөреп китте. Бу хәл шимбэ көнне булганга күрә, 10 яһүдлэр савыккан кешегә: - Бүген шимбэ көн, канун буенча, син ятагыңны алып йөрергэ тиеш түгел, - диделэр. 11 Ул аларга: - Мине савыктырган кеше миңа: «Ятагыңны ал да йөр», - дип эйтте, - диде. 12 Аңардан: - Сиңа: «Ятагыңны ал да йөр», - дип эйткэн кеше кем ул? - дип сорадылар. 13 Гайсэ җыелган халык арасына кереп югалганга күрэ, савыккан кеше Аның кем икэнен белми иде. 14 Соңрак, Гайсэ аны Алла Йортында очратып: - Менэ син савыктың. Сиңа тагын да начаррак булмасын өчен, моннан соң инде гөнаһ эшлэмэ, - диде. 15 Ул кеше, яһүдлэр янына барып, үзен савыктыручының Гайсэ икэнен сөйлэде.

## Атасы норсэ эшлэсэ, Улы да шуны эшлэр

16 Шушы эшне шимбә көнне эшлэгэне өчен, яһүдлэр Гайсэне эзэрлекли башладылар. 17 Гайсэ аларга: - Минем Атам һэрвакыт эшлэгэнгә күрэ, Мин дэ эшлим, - дип җавап бирде. 18 Яһүдләр Аны шимбә көнен бозуы өчен генә түгел, бэлки бигрэк тэ Алланы Үземнең Атам дип атап, Үзен Аллага тиңлэгэне өчен дә үтерергэ телэделэр. 19 Гайсэ аларның бу телэклэренэ: - Сезгә чын дөресен эйтэм: Атасының нэрсә эшлэвен күрмичә, Улы Үзе һичнэрсә дә эшли алмас, - диде. - Атасы нәрсә эшлэсэ, Улы да шуны эшләр. 20 Ата Үзенең Улын ярата һэм Үзе эшлэгән һэр эшен Аңа күрсэтэ. Ул Аңа сезнең исегез китәрлек моннан да

зуррак эшләр күрсәтер әле. 21 Ата, үлгәннәрне терелтеп җанландырган кебек,
Улы да, кемне теләсә, шуны җанландыра. 22-23 дта беркемне дә хөкем итми, ә
Үзен ихтирам иткән кебек, Улын да һәркем ихтирам итсен өчен, Ул бөтен хөкемне
Улына тапшырды. Кем Улын ихтирам итми, шул Аны җибәргән Атаны да ихтирам
итми. 24 Сезгә чын дөресен әйтәм: Минем сүземне тыңлап, Мине Җибәрүчегә
иман китерүче мәңгелек тормышка ия булган кеше хөкемгә килмәячәк, чөнки ул
инде үлемнән тормышка күчте. 25 Сезгә чын дөресен әйтәм: Алла Улының авазын
ишетеп үлгәннәр тереләчәк вакыт җитә һәм килеп җитте дә инде. 26 Үзендә
тормыш булган кебек, Улында да булсын дип Ата Улына тормыш бирде. 27 Ата
Улына хөкем итү вәкаләтен дә бирде, чөнки Ул - Адәм Улы. 28-29 Моңа
гаҗәпләнмәгез: чөнки кабердәгеләрнең һәммәсе, Алла Улының авазын ишетеп,
яхшылык эшләгәннәр - яшәү өчен, ә явызлык эшләгәннәр - хөкем ителү өчен
каберләрдән чыгачак вакыт якынлашып килә. 30 Мин Үземнән-Үзем бернәрсә
эшли алмыйм. Ничек ишетсәм, шулай хөкем итәм, һәм Минем хөкемем гадел,
чөнки Мин Үз ихтыярымны түгел, бәлки Мине Җибәрүченең ихтыярын эзлим.

## Гайсә хакында шаһәдәтләр

31 Әгәр дә Мин Үзем Үз хакымда шаһәдәт бирәм икән, Минем шаһәдәтем бернигә
дә тормас иде. 32 Минем хакта шаһәдәт бирүче башка берәү бар, һәм Мин беләм:
Аның Минем хакта биргән шаһәдәте хак. 33 Сез Яхъя пәйгамбәр янына кешеләр
җибәрдегез, һәм ул хакыйкать хакында шаһәдәт бирде. 34 Ләкин Мин кешеләрнең
шаһәдәтенә мохтаҗ түгел, ә боларны сез котылсын өчен сөйлим. 35 Яхъя янучы
һәм нур бирүче яктырткыч иде, о сез аның яктылыгы астында бераз вакыт кына
куанырга теләдегез. 36 Әмма Минем шаһәдәтем Яхъяныкыннан зуррак: Мин
Атаның төгәлләргә дип Миңа биргән эшләрен башкарам. Мин эшләгән шул эшләр
Мине Атам җибәргән булуына шаһәдәт бирәләр. 37 Мине җибәргән Ата Минем
хакта Үзе шаһәдәт бирде. Ә Аның тавышын сез беркайчан ишетмәдегез, йөзен
күрмәдегез. 38 Сездә Аның сүзе тормый, чөнки сез Ул җибәргән Затка иман
китермисез. 39 Сез, мәңгелек тормыш алырга теләгәнгә күрә, Изге Язмада
язылганнарны тикшерәсез, ә алар нәкъ Минем хакта шаһәдәт бирәләр. 40 Әмма
сез тормыш алу өчен Минем яныма килергә теләмисез. 41 Кешеләрнең Мине
данлауларына мохтаҗлыгым юк, 42 ә сезнең Алланы яратмавыгызны Мин беләм.
43 Мин Атам исеменнән килдем - сез Мине кабул итмисез, ә үз исеменнән килгән
башка берәүне кабул итәсез. 44 Сез бер-берегездән дан кабул итәсез, ә бер
Алладан булган данны эзләмисез. Шулай булгач, сез ничек итеп иман китерә
алырсыз икән? 45 Мин Атам алдында сезне гаепләрмен дип уйламагыз. Сезне
гаепләүче - сез өмет баглаган Муса. 46 Сез Мусага ышансагыз, Миңа да иман
китерер идегез, чөнки ул Минем хакта язды. 47 Аның язганнарына ышанмыйча
торып, сез Минем сүзләремә ничек ышанырсыз соң? Биш меңне ашату 6:1
Шуннан соң Гайсә Галилея диңгезенең аръягына китте. Ул диңгез, шулай ук,
Тибериас күле дип тә атала иде. 2 Авыруларны савыктырган могҗизалы
галәмәтләрен күреп, Аның артыннан бик күп халык иярде. 3 Гайсә, тауга менеп,

шәкертләре белән бергә утырды. 4 Яһүдләрнең Коткарылу бәйрәме якынлашып килә иде. 5 Гайсә күтәрелеи карады һәм Үзенә таба күп халыкның килүен күреп, Филипка: - Аларны ашату өчен кайдан икмәк сатып алырбыз икән? - диде. 6 Ул бу сүзләрне Филипны сынау өчен генә әйтте, чөнки нәрсә эшләячәген Үзе белә иде. 7 Филип: - Аларның һәрберсенә аз-аз гына бирү өчен дә ике йөз динарлык икмәк җитмәс, - дип җавап бирде. 8 Шәкертләренең берсе, Симон Питернең энесе Әндри, Аңа: 9 - Монда бер малайның биш арпа икмәге һәм ике балыгы бар, әмма мондый күп халык өчен ул нәрсә инде? - диде. 10 Гайсә: - Аларга утырырга кушыгыз, - диде. Ул урында исә, чирәм күп иде. Шулай итеп, биш мең чамасы ир чирәмгә утырды. 11 Гайсә, икмәкне алып, шөкрана итеп, утыручыларга өләште; балыкларны да шулай ук иткәннән соң, һәркемгә теләгән кадәр бирде. 12 һәммәсе ашап туйгач, Ул Үзенең шәкертләренә: - Калган сыныкларны җыеп алыгыз, бернәрсә дә әрәм булмасын, - диде. 13 Кешеләр ашаган биш арпа икмәгеннән калган сыныкларны җыеп, унике кәрзингә тутырдылар. 14 Гайсә эшләгән могҗизалы галәмәтне күреп, кешеләр: - Дөньяга килергә тиеш булган Пәйгамбәр, чынлап та, Шушыдыр, - диештеләр. 15 Гайсә исә, аларның Үзен көч белән патша итеп куярга теләгәннәрен белеп, тагын, ялгыз гына, тауга менеп китте.

## Гайсәнең диңгез өстеннән атлап килүе

16 Кич җиткәч, Аның шәкертләре диңгез буена төштеләр дә, 17 көймәгә утырып, диңгезнең аръягына, Капарнаумга таба йөзеп киттеләр. Караңгы төште, ә Гайсә исә һаман күренмәде. 18 Диңгездә каты җил купканлыктан, дулкыннар көчәйде. 19 Егерме биш яки утыз стадия чамасы киткәннән соң алар, диңгез өстеннән атлап көймәгә якынлашып килүче Гайсәне күреп, куркып калдылар. 20 Әмма Гайсә аларга: - Бу Мин, курыкмагыз, - диде. 21 Алар Аны көймәгә алырга теләделәр, ләкин нәкъ шул чакта көймә алар бара торган ярга килеп туктады.

## Гайсә - тормыш икмәге

22 Икенче көнне дә халык диңгез ярында тора иде әле. Алар анда бер генә көймә булуын, ул көймәгә шәкертләрнең генә утырып китүен, ә Гайсәнең анда утырмаганын күргәннәр иде. 23 Раббы шөкрана итеп биргән икмәкне ашаган урынга Тибериас шәһәреннән башка көймәләр дә килеп туктады. 24 Шулай итеп, халык анда Гайсәнең дә, Аның шәкертләренең дә юклыгын күргәч, көймәләргә утырып, Капарнаумга Гайсәне эзләргә китте. 25 Аны диңгезнең аръягында эзләп тапкач: - Остаз! Син монда кайчан килдең? - дип сорадылар. 26 Гайсә аларга: - Сезгә чын дөресен әйтәм: сез Мине могҗизалы галәмәтләр күргәнегез өчен түгел, бәлки туйганчы икмәк ашаганыгыз өчен эзлисез. 27 Фани ризык өчен түгел, бәлки мәңгелек тормыш бирә торган ризык өчен тырышыгыз. Аны сезгә Адәм Улы бирәчәк, чөнки Алла Ата Үзенең тамгасын Аңа салды, - диде. 28 Аннан соң алар: - Алла эшләрен башкару өчен безгә нәрсә эшләргә кирәк? - дип сорадылар. 29 - Алланың эше менә шул: Ул Кемне җибәргән булса, сез Шуңа иман китерегез, -

дип җавап бирде Гайсә. 30 Алар Аңа әйттеләр: - Без Сиңа иман китерерлек нинди
галәмәт күрсәтерсең? Син нәрсә эшләрсең? 31 Изге Язмада: «Ул аларга ашар
ечен күктән икмәк бирде», - дип язылганча, безнең атабабаларыбыз чүлдә манна
ашаганнар. 32 Гайсә аларга: - Сезгә чын дөресен әйтәм: ул икмәкне сезгә Муса
бирмәде. Ә сезгә Минем Атам күктән хак икмәк бирә. 33 Күктән иңеп, дөньяга
тормыш Бирүче - Ул Алла икмәге, - диде. 34 Алар Гайсәгә: - Әфәндем! Безгә
һәрвакыт шундый икмәк бирче, - диделәр. 35 Гайсә исә, аларга әйтте: - Мин -
тормыш икмәге: Миңа килүче һичкайчан ачыкмас, Миңа иман китерүче һичкайчан
сусамас. 36 Ләкин Мин сезгә: сез Мине күрдегез, әмма Миңа иман китермисез, -
дидем. 37 Атам Миңа юллаган һәркем Миңа киләчәк һәм Миңа килүчене
һичкайчан куып җибәрмәячәкмен, 38 чөнки Мин Үз ихтыярымны түгел, бәлки Мине
җибәргән Атам ихтыярын башкару өчен күктән иңдем. 39 Мине җибәргән Атамның
ихтыяры исә шул: Ул Миңа биргән беркемне дә югалтмаска, бәлки кыямәт
көнендә үледән терелтергә тиешмен.40 Мине җибәргән Атамның ихтыяры шул:
Улын күреп, Улына иман китерүче һәркемнең мәңгелек тормышы булсын. Мин
аны кыямәт көнендә терелтеп торгызачакмын. 41 Яһүдләр, Аның «Мин - күктән
иңгән икмәк» дигән сүзләренә ризасызлык белдереп, үзара: 42 - Бу Йосыф улы
Гайсә түгелме соң? Без Аның атасын да, анасын да беләбез бит. Ничек Ул: «Мин
күктән индем», - дип сөйли ала икән? - диештеләр. 43 Гайсә аларга җавап бирде:
- Үзара сукранышмагыз: 44 Мине җибәргән Ата алып килмәсә, Минем яныма
беркем дә килә алмый. Мин аны кыямәт көнендә терелтеп торгызачакмын. 45
Пәйгамбәрләрнең язмаларында: «һәммәсе дә Алла тарафыннан өйрәтеләчәк», -
дип язылган. Атадан ишетеп өйрәнүче һәркем Миңа килә. 46 Бу эле кем дә булса
Атаны күргән дигән сүз түгел, бәлки Алладан Килүче генә Атаны күрде. 47 Сезгә
чын дөресен әйтәм: Миңа иман китерүченең мәңгелек тормышы бар. 48 Мин -
тормыш икмәге. 49 Сезнең аталарыгыз чүлдә манна ашадылар һәм үлделәр. 50
Күктән иңүче икмәк исә шундый ки, аны ашаучы үлмәс. 51 Мин - күктән иңгән тере
икмәк, бу икмәкне ашаучы мәңге яшәр. Мин бирәчәк икмәк исә - ул Минем тәнем.
Мин аны дөнья яшәсен өчен бирәчәкмен. 52 Шуннан соң яһүдләр, ачуланышып: -
Бу Кеше Үзенең тәнен безгә ашар өчен ничек бирә алыр икән? - дип үзара бик
каты бәхәсләштеләр. 53 Гайсә исә, аларга әйтте: - Сезгә чын дөресен әйтәм:
Адәм Улының тәнен ашамасагыз һәм Аның канын эчмәсәгез, сезнең үзегездә
тормыш булмаячак. 54 Минем тәнемне ашап Минем канымны эчүченең мәңгелек
тормышы бар. Мин аны кыямәт көнендә терелтеп торгызачакмын. 55 Минем тәнем
- чын ризык, Минем каным - чын эчемлек. 56 Минем тәнемне ашап, Минем
канымны эчүче Миндә кала, Мин аңарда калам. 57 Мине тере Атам җибәрде һәм
Мин Атам аша яшим, шулай ук Мине ашаучы да Минем аша яшәячәк. 58 Бу -
күктән иңгән икмәк. Ул икмәк сезнең аталарыгыз ашаган манна кебек түгел: алар
үлгәннәр. Ә бу икмәкне ашаучы мәңге яшәячәк. 59 Ул боларны Капарнаумда
өйрәткән вакытта синагогада сөйләде.

Сез до киторго теломисезме?

60 Гайсэнең күп шэкертлэре, боларны ишеткэннэн соң: - Нинди авыр сүзлэр!
Моны кем тыңлый алсын? - диделэр. 61 Әмма Гайсә күңеленнән шәкертләренең
сукрануларын белеп: - Сезне шушы рэнҗетэме! 62 Адэм Улының элек булган
урынына күтэрелүен күрсэгез нэрсэ булыр? 63 Тик Рух кына тормыш бирэ,
кешенең монда көче юк; Мин сезгэ сөйлэгэн сүзлэр - рух һэм тормыш. 64 Эмма
сезнең арагызда иман китермәүчелэр дэ бар, - дип эйтте. Чөнки Гайсэ кемнең
иман китермэвен һэм кемнең Үзенә хыянэт итэчэген баштан ук белде. 65 Ул сүзен
дэвам итеп: - Менэ шуның өчен, Мин сезгэ Атам җибәрмэсэ, Минем яныма
беркемнең дэ килэ алмаячагын эйттем, - диде. 66 Шул вакыттан, Гайсэнең күп
кенэ шэкертлэре Аннан аерылып киттелэр һэм башка Аның белэн бергэ
йөрмэделэр. 67 Шуннан соң, Гайсә унике шәкертеннән: - Сез дэ китэргэ
теләмисезме? - дип сорады. 68 Симон Питер Аңа: - Раббым! Без кемгэ барыйк
соң? Мәңгелек тормыш сүзлэре Синдэ бит. 69 Без Сиңа иман китерэбез, Сине
Алланың Изге Заты дип таныйбыз, - дип җавап бирде. 70 Гайсэ аларга: - Мин сез
уникене сайлап алдым түгелме? Эмма сезнең арагызда берегез иблис, - диде. 71
Ул соңрак Үзенә хыянәт итәчәк уникенең берсе булган Симон улы Яһүд Искариот
хакында әйтте.

## Гайсэ һэм Аның энелэре

7:1 Шуннан соң, яһүдләр Гайсәне үтерергә эзләгәнлектән, Ул Яһүдиядә булырга
теләмәде. Шуңа күрэ, Гайсә Галилеядә калырга булды. 2 Яһүдләрнең Чатыр Кору
бәйрэме якынлашкач, 3 энелэре Аңа: - Галилеядэн Яһүдиягэ бар, Синең эшләгән
эшләреңне шәкертләрең дә күрсен. 4 Беркем дә эшен яшереп эшләми, бәлки
үзен таныту юлын эзләр; әгәр андый эшләр эшлисең икән, Үзеңне дөньяга күрсәт,
- дип әйттелэр. 5 Аңа хәтта энеләре дә иман китермәделәр. 6 Гайсә аларга әйтте:
- Минем вакыт килеп җитмәде әле, ә сезнең өчен һәркайчан вакыт. 7 Сезгә дөнья
нәфрәт белән карамый, ә Миңа нәфрәтен күрсәтә, чөнки Мин аның эшләре явыз
булганлыгына һәрвакыт шаһәдәт биреп торам. 8 Сез бу бәйрәмгә барыгыз, э Мин
бармыйм, чөнки Минем вакыт килеп җитмәде әле. 9 Ул аларга шулай дип
Галилеядә калды, 10 эмма энеләре киткәч, яшерен рәвештә, Ул да бәйрәмгә
барды.

## Гайсэ Чатыр Кору бэйрэмендэ

11 Яһүдлэр исэ: - Ул кайда икэн? - дип, Аны бәйрәмдә эзләп йөрделәр. 12 Аның
хакында халык арасында күп сүзләр йөрде. Кайберләре: - Ул яхшы, - диделәр,
башкалары исә: - Юк, Ул халыкны аздыра, - дип сөйләделәр. 13 Әмма,
яһүдләрдән куркып, Аның хакында беркем дә ачык итеп сөйләмәде. 14 Гайсә
бәйрәм уртасында Алла Йортына кереп ейрәтә башлады. 15 Яһүдләр: - Бу кеше
бер дэ укымыйча, кайдан шундый белем алган икән? - дип гаҗәпләнделәр. 16
Гайсэ аларга: - Минем өйрәтүем Үземнеке түгел, бэлки Мине Җибэрүченеке. 17
Кем дә кем Аның ихтыярын башкарырга теләсэ, бу ейрәтүнең Алладанмы, яки

Мин Үземнән сөйлимме икәнен белер. 18 Үз исеменнән сөйләүче үзенә дан эзли,
ә Үзен Җибәрүченең данын Эзләүче эчкерсез һәм Аңарда ялган юк. " Муса сезгә
канунны бирде түгелме? Э сезнең берегез дэ аны үтәми. Ни өчен Мине үтерергә
йөрисез? - дип әйтте. 20 Кешеләр: - Сиңа җен кагылдымы эллэ? Кем Сине
үтерергә йөри? - диделәр. 21 Гайсә, сүзен дэвам итеп, аларга: - Мин бер эш
эшлэдем һәм сез һәммәгез шуңа гаҗәпләнәсез. 22 Муса сезгә сөннәт бирде, -
гэрчә ул Мусадан түгел, бәлки аталардан килә, - һәм сез шимбә конне дэ ир
баланы сеннәткә утыртасыз. 23 Муса кануны бозылмасын дип, шимбә көнне дэ ир
бала сөннәткә утыртыла икэн, шимбэ көнне бер кешене бәтенлэй савыктырган
өчен, нигэ Миңа ачуыгыз килэ? 24 Тышкы күренешкә генэ карап хөкем итмәгез,
бәлки дөрес хөкем итегез.

## Гайсэ - Мэсихме?

25 Шунда кайбер иерусалимлылар бер-берсенэ: - Бу эллә яһүдлэр үтерергә
теләгән Кешеме? 26 Әнә, Ул ачыктан-ачык сөйли, ә алар Аңа бер сүз дә
эйтмиләр: әллә башлыклар Аны чыннан да Мәсих дип уйлыйлармы икән? 27
Эмма без Аның кайдан икәнен беләбез. Э инде Мәсих килгәндә, Аның кайдан
икэнлеген беркем дә белмәс, - диделәр. 28 Гайсә, Алла Йортында әйрэткәндә
игълан итеп: - Сез Мине беләсез һәм кайдан икәнемне дә беләсез. Ләкин Мин
Үземнэн Үзем килмэдем, һәм Мине Җибәрүче хак. Сез Аны белмисез, 29 ә Мин
Аны беләм, чөнки Мин Аннан килдем, Мине Ул җибәрде. 30 Алар Гайсэне тотып
алырга телЭделәр, ләкин берсе дә Аңа кул тидермәде, чөнки Аның вакыты килеп
җитмэгэн иде әле. 31 Халык арасында исә, күп кешеләр Аңа иман китерделәр
һәм: - Мэсих килгэч, бу Зат күрсәткәннән дә күбрәк илаһи билгеләрне күрсәтерме
икән? - диештеләр. 32 Фарисейләр халыкның Гайсэ хакында шулай
пышылдашканнарын ишеткәннән соң, баш руханилар белән берләшеп, Аны тотып
алу әчен, тәртип саклаучыларны җибәрделәр. 33 Гайсә аларга: - Мин сезнең
арагызда озак булмам, тиздән Үземне Җибәрүче янына кире кайтачакмын. 34
Мине эзлэрсез, эмма тапмассыз. Мин булачак урынга сез килә алмассыз, - дип
әйтте. 35 Шунда яһүдләр үзара: - Ул без таба алмаслык нинди урынга китмәкче
була икэн? Эллэ Ул, греклар арасына таралып яшәүчеләр янына китеп,
грекларны өйрәтергә телиме икән? 36 Аның: «Мине эзләрсез, әмма тапмассыз.
Мин булачак урынга сез килэ алмассыз», - дигән сүзләре нәрсәне аңлата икән? -
диделәр. 37 Бэйрәмнең соңгы, бөек кенендә Гайсә торып игълан итте: - Кем
сусаса, Миңа килсен дә эчсен. 38 Кем Миңа иман китерсә, Изге Язмада
әйтелгәнчә, «аның күңел түреннән елгалар булып тереклек суы агачак». 39 Ул
моны Үзенә иман китергәннәр алачак Рух хакында эйтте, чәнки Гайсэ эле данлы
ителмәгәнгә күрә, аларга Изге Рух бирелмәгән иде. 40 Аның бу сүзләрен тыңлаган
халык арасында кайберләре: - Ул чынлап та вәгъдә ителгән Пәйгамбәр, -
диделәр. 41 Берләре: - Бу - Мәсих. Ә башкалары: - Мәсих Галилеядән килер
микән? 42 Изге Язмада: Мәсих Давыт нэселеннэн булачак һәм ул туган шәһәрдән
- Битлеһемнән киләчәк, - дип язылган түгелме? диделәр. 43 Шулай итеп, халык

арасында Аның хакында бәхәс чыкты. 44 Аларның кайберләре Аны тотып алырга
теләделәр, ләкин берсе дә Аңа кул тидермәде. 45 Тәртип саклаучылар, баш
руханилар һәм фарисейләр янына кайткач, алардан: - Ни өчен Аны тотып
китермәдегез? - дип сорадылар. Тегеләр: 46 - Бу Кеше сөйләгән кебек, берәүнең
дә һичкайчан сөйләгәне юк, - дип җавап бирделәр. 47 Фарисейләр аларга: - Әллә
сез дә алдандыгызмы? 48 Башлыклардан яки фарисейләрдән кем дә булса Аңа
иман китердеме? 49 Ләкин канунны белмәгән бу халык ләгънәт ителгән. 50
Фарисейләрнең берсе - элегрәк Гайсә янына килеп киткән Никәдим - аларга: 51 -
Безнең канун кешене башта тыңламыйча һәм аның ни эшләгәнен белмичә аны
хөкем итәме? - диде. 52 Аңа: - Әллә син дә Галилеядәнме? Тикшереп кара һәм
күрерсең: Галилеядән һич тә пәйгамбәр чыкмас, - дип җавап бирделәр. 53
Барысы да өйләренә таралгач.

## Уйнишлыкта тотылган хатын

8:1 Гайсә Зәйтүн тавына китте. 2 Иртә белән Ул яңадан Алла Йортына килгәч,
Аның янына күп халык җыелды. Ул, утырып, аларны өйрәтә башлады. 3 Шулчак
канунчылар һәм фарисейләр уйнашлыкта тотылган бер хатынны, халык янына
китереп, уртага бастырып куйдылар 4 һәм Гайсәгә: - Остаз! Бу хатын зина
кылганда тотылды. 5 Муса канунда мондыйларны таш атып бәреп үтерергә әмер
бирә, ә Син нәрсә әйтерсең? - диделәр. 6 Алар моны, Гайсәне сынау өчен, Аны
гаепләргә берәр сылтау табарбыз дигән уй белән әйттеләр. Әмма Гайсә, түбән
иелеп, бармагы белән җиргә яза башлады. 7 Алар Аннан сорауларын дәвам
иткәнгә, Ул, торып басып, аларга: - Сезнең кайсыгыз гөнаһсыз, шул башлап аңа
таш атсын, - диде. 8 һәм, тагын түбән иелеп, җиргә язуын дәвам итте. 9 Алар исә,
моны ишеткәч, өлкәннәреннән башлап бер-бер артлы чыгып киттеләр. Гайсә
уртада басып торган хатын белән ялгыз калды. 10 Гайсә, торып басып: - Сеңелем!
Алар кайда? Сине беркем дә хөкем итмәдеме? - дип сорады. 11 Хатын: - Беркем
дә, Әфәндем! - диде. Гайсә аңа: - Мйн дә сине хөкем итмим: бар, башка гөнаһ
эшләмә, - диде.

## Гайсо дөньяга яктылык

12 Гайсә халыкка тагын: - Мин - дөньяга яктылык. Минем артымнан баручы
караңгылыкта йөрмәячәк, бәлки аның тормыш бирүче яктылыгы булачак, - дип
әйтте. 13 Шуннан соң, фарисейләр Аңа: - Син Үз хакыңда Үзең шаһәдәт бирәсең,
Синең шаһәдәтең хак түгел, - диделәр. 14 Гайсә аларга: - Мин Үз хакымда Үзем
шаһәдәт бирсәм дә, Минем шаһәдәтем хак, чөнки кайдан килеп кая баруымны
беләм, ә сез Минем кайдан килеп кая баруымны белмисез. 15 Сез кешеләрнең
үлчәме буенча хөкем итәсез, ә Мин беркемне дә хөкем итмим. 16 Мин хөкем итсәм
дә, Минем хөкемем хак, чөнки Мин ялгыз түгел, бәлки Мин Үземне җибәргән Ата
белән бергә. 17 Сезнең кануныгызда да: «Ике кешенең шаһәдәте хак», - дип
язылган. 18 Мин Үз хакымда Үзем шаһәдәт бирәм һәм Минем хакта Мине

җибәргән Ата да шаһәдәт бирә, - дип җавап бирде. 19 Шуннан соң Гайсәдән: -
Синең атаң кайда? - дип сорадылар. Гайсә: - Сез Мине дә, Минем Атамны да
белмисез. Әгәр Мине белсәгез, сез Минем Атамны да белер идегез, - диде. 20
Гайсә бу сүзләрне Алла Йортында өйрәткәндә сәдака сандыгы янында әйтте.
Берсе дә Аңа кул тидермәде, чөнки Аның вакыты килеп җитмәгән иде әле.

## Мин китәчәк урынга сез килә алмассыз

21 Гайсә аларга янә: - Мин китәм, сез Мине эзләрсез һәм үзегезнең гөнаһыгыз
эчендә үләрсез. Мин китәчәк урынга сез килә алмассыз, - дип әйтте. 22 Яһүдләр:
- Ул Үзен Үзе үтерәчәк микәнни? Чөнки: «Мин китәчәк урынга сез килә алмассыз»,
- ди бит, - диештеләр. 23 Ул аларга: - Сез түбәннән, Мин югарыдан. Сез бу
дөньяныкы, Мин бу дөньяныкы түгел, - диде. 24 - Сез Минем мәңге бар икәнемә
ышанмасагыз, үз гөнаһларыгыз эчендә үләрсез. Шуңа күрә Мин сезгә: «Сез
гөнаһларыгыз эчендә үләрсез», - дидем. 25 Шуннан соң, Аннан: - Кем соң Син? -
дип сорадылар. - Мин сезгә Үземнең кемлегемне инде күптән әйтәм, - диде
аларга Гайсә. 26 - Сезнең хакта күп сөйләп сезне хөкем итә алыр идем. Әмма
Мине Җибәрүче хак, һәм Мин, Аннан нәрсә ишетсәм, шуны дөньяга сөйлим. 27
Алар Гайсәнең Ата хакында сөйләвен аңламадылар. 28 Гайсә аларга әйтте: - Сез
Адәм Улын күтәргән вакытта, Минем мәңге бар икәнемне һәм Минем Үзлетемнән
һичнәрсә эшләмәвемне, бәлки, Атам ничек өйрәткән булса, шулай сөйләвемне
белерсез. 29 Мине Җибәрүче Минем белән. Атам Мине ялгыз калдырмады, чөнки
Мин һәрвакыт Ул теләгән эшләрне генә эшлим. 30 Ул боларны сөйләгән чакта,
күпләр Аңа иман китерделәр.

## Ибраһимның балалары

31 Гайсә Үзенә иман китергән яһүдләргә: - Минем сүзләремне тотсагыз, чыннан
да Минем шәкертләрем булырсыз. 32 Хакыйкатьне белерсез һәм хакыйкать сезне
ирекле итәр, - дип әйтте. 33 Аңа: - Без Ибраһим нәселеннән, - диделәр, - һәм
һичкайчан да беркемнең дә колы булмадык. Ничек соң Син: «Ирекле булырсыз», -
дисең? 34 - Сезгә чын дөресен әйтәм: гөнаһ эшләүче һәркем - гөнаһның колы. 35
Кол өйдә мәңге тормый, ә атаның улы мәңге тора. 36 Шулай итеп, Улы сезне
ирекле итсә, сез чын мәгънәсендә ирекле булачаксыз. 37 Мин сезнең Ибраһим
нәселеннән булуыгызны беләм, әмма Минем сүзләремә сездә урын булмаганга
күрә, Мине үтерергә йөрисез. 38 Мин Атам янында күргәннәрем турында сөйлим,
ә сез үз атагыз янында ишеткәннәрне эшлисез, - диде аларга Гайсә. 39 Алар
җавап биреп: - Безнең атабыз - Ибраһим, - диделәр. Гайсә аларга әйтте: - Сез
Ибраһим балалары булсагыз, Ибраһим эшләрен эшләр идегез. 40 Ә хәзер Мине,
Алладан ишеткән хакыйкатьне сөйләгән Кешене, үтерергә йөрисез. Ибраһим моны
эшләмәде. 41 Сез үз атагызның эшләрен эшлисез. Алар Аңа: - Без уйнаштан
тумаган, безнең Атабыз бер генә: Ул - Алла, - диделәр. 42 Гайсә аларга әйтте: -
Сезнең атагыз Алла булса, сез Мине яратыр идегез, чөнки Мин Алладан килдем.

Мин Үзлегемнән килмәдем, бәлки Мине Ул җибәрде. 43 Ни өчен сез Мин сөйләгәннәрне аңламыйсыз? Чөнки сез Минем сүземне тыңлый алмыйсыз. 44 Сезнең атагыз - иблис, һәм сез атагызның теләкләрен үтәргә телисез. Ул, баштан ук, кеше үтерүче булып, хакыйкатьне тотмады һәм хәзер дә тотмый, чөнки аңарда хакыйкать юк. Ул ялган сөйләгән вакытта үзенекен сөйли, чөнки ул - ялганчы һәм ялганның атасы. 45 Ә Мин хакыйкатьне сөйләгәнгә күрә сез Минем сүзләремә ышанмыйсыз. 46 Минем гөнаһта гаепле икәнемне сезнең кайсыгыз күрсәтә алыр? Әгәр хакыйкатьне сөйлим икән, ни өчен Минем сүзләремә ышанмыйсыз? 47 Кем Алладан булса, ул Алла сүзләрен тыңлар; ә сез, Алладан булмаганга күрә, тыңламыйсыз.

## Гайсә һәм Ибраһим

48 Моңа яһүдләр: - «Син самарияле, Синең эчеңдә җен бар», - дип әйтүебез дөрес түгелме әллә? - диделәр. 49 Гайсә җавап бирде: - Миндә җен юк. Мин Атамны хөрмәт итәм, ә сез Мине хур итәсез. 50 Хәер, Мин Үземә дан эзләмим, ә Эзләүче башка Берәү бар һәм Ул хөкем итә. 51 Сезгә чын дөресен әйтәм: кем Минем сүземне тота, ул һичкайчан үлем күрмәячәк. 52 Яһүдләр Аңа: - Менә хәзер Синдә җен барлыгына һич шигебез калмады: Ибраһим да, пәйгамбәрләр дә үлделәр, ә Син: «Кем Минем сүземне тота, ул беркайчан да үлемне татымас», - дисең. 53 Син безнең атабыз Ибраһимнан да бөегрәкме? Ул үлгән, пәйгамбәрләр дә үлгәннәр. Син Үзеңне кем дип санайсың? 54 Гайсә җавап бирде: - Мин Үземне Үзем данлыйм икән, Минем даным буш булыр. Мине сез «Аллабыз» дип атаган Минем Атам данлый. 55 Сез Аны белмисез, ә Мин Аны беләм. Мин Аны белмим дисәм, сезнең кебек ялганчы булыр идем; әмма Мин Аны беләм һәм Аның сүзен тотам. 56 Сезнең атагыз Ибраһим Минем көнемне күрәчәгенә шатланды. Ул аны күреп куанды. 57 Яһүдләр Аның бу сүзләренә: - Сиңа әле илле яшь тә юк, ә Син Ибраһимны күрдеңме? - диделәр. 58 Гайсә аларга әйтте: - Сезгә чын доресен әйтәм: Ибраһим булганга кадәр Мин Бар. 59 Шул чакта алар, Аңа ату өчен кулларына ташлар алдылар, әмма Гайсә, яшеренеп, Алла Йортыннан чыгып китте.

## Тумыштан сукырның күрә башлавы

9:1 Гайсә, үтеп барышлый, тумыштан ук сукыр бер кешене күрде. 2 Шәкертләре Аннан: - Остаз! Бу кешенең сукыр булып тууы кемнең гөнаһыннан: бу кеше үзе гөнаһ кылганмы, әллә ата-анасымы? - дип сорадылар. 3 Гайсә җавап бирде: - Бу кеше үзе дә, ата-анасы эшләгән гөнаһ өчен дә сукыр түгел. Ул аның авыруы аркылы Алла эшләре күренсен өчен сукыр булып туды. 4 Көн үткәнче, без Мине Җибәрүченең эшләрен башкарырга тиешбез. Төн килә, ул чакта һичкем берни эшли алмас. 5 Мин дөньяда вакытта, Мин - дөньяга яктылык. 6 Шулай дип, Ул җиргә төкерде, төкереге белән изеп лай ясап, шул лайны сукырның күзләренә сөртте дә 7 аңа: - Силоам буасына барып юын, - диде. (Силоам - «Җибәрелгән»

дигән мәгънәдә.) Ул барып юынды һәм күзләре күрә торган булып кайтты. 8 Аның
күршеләре һәм элек аның хәер сорашып утьфганын күргән кешеләр: - Бу соң,
теге, хәер сорашып утырган кеше түгелме? - диделәр. 9 Кайберләре: - Бу - шул. Э
кайберләре: - Шуңа охшаган, - диделәр. Ул үзе исә: - Мин шул кеше, - диде. 10
Аннан: - Күзләрең ничек ачылды соң? - дип сорадылар. 11 Ул җавабында: - Гайсә
атлы Кеше лай ясап күзләремә сөртте, аннан: «Силоам буасына барып юын», -
диде. Мин барып юынган идем, күзләрем ачылды, - диде. 12 Аннан: «Ул Кеше
кайда?» - дип сорагач, ул: - Мин белмим, - дип җавап бирде. 13 Элек сукыр
булган бу кешене фарисейләр янына алып бардылар. 14 Гайсә лай ясап
сукырның күзләрен ачкан көн - шимбә көн иде. 15 Фарисейләр да аннан ничек
күрә башлавы хакында сораштылар. Ул аларга: - Ул минем күзләремә лай
сылады, мин юындым да күрә башладым, - диде. 16 Кайбер фарисейләр: - Бу
Кеше шимбә көнне тотмый, шуңа күрә Ул Алладан түгел, - дип әйттеләр. Э
башкалары: - Гөнаһлы кеше мондый могҗизалы галәмәтләрне ничек эшли алсын?
- диделәр. һәм алар арасында бәхәс чыкты. 17 Элеге сукырдан: - Син Аның
турында нәрсә әйтерсең, Ул бит синең күзләреңне ачты? - дип сорадылар. - Ул -
пәйгамбәр, - дип җавап бирде теге кеше. 18 Әмма яһүдләр аның сукыр булганына
һәм күрә башлавына ышанмаганга күрә, күзләре ачылган кешенең ата-анасын
чакырып, 19 алардан: - Тумыштан сукыр дигән улыгыз шушымы? Ул хәзер ничек
күрә? - дип сорадылар. 20 Ата-анасы аларга: - Без аның улыбыз икәнен һәм сукыр
булып туганын беләбез. 21 Э аның ничек күрә башлавын да, күзләрен кем
ачканын да белмибез. Ул инде балигъ булган, үзеннән сорагыз, үзе хакында үзе
сөйләсен, - дип җавап бирделәр. 22 Сукырның ата-анасы, яһүдләрдән курыкканга
күрә, шулай диделәр. Чөнки яһүдләр, Гайсәнең Мәсих икәнен икърар итүче
һәркемне синагогадан аерырга дип сүз куешкан иделәр. 23 Шунлыктан аның
ата-анасы: «Ул инде балигъ булган, үзеннән сорагыз», - диделәр. 24 Шулай итеп,
алар, элек сукыр булган кешене икенче тапкыр чакырып, аңа: - Алланы ихтирам
ит! Без ул Кешенең гөнаһлы икәнен беләбез, - диделәр. 25 Ул аларга җавабында:
- Ул гөнаһлымы, түгелме, анысын белмим. Шуны гына беләм: мин сукыр идем, э
хәзер күрәм, - дип әйтте. 26 Алар тагын аннан: - Ул нәрсә эшләде? Синең
күзләреңне ничек ачты? - дип сорадылар. 27 Ул аларга: - Мин инде сезгә
сөйләдем, ә сез тыңламадыгыз. Ни өчен тагын ишетергә телисез? Эллә сез дә
Аның шәкертләре булырга телисезме? - дип җавап бирде. 28 Алар аңа, бик
ачуланып: - Син - Аның шәкерте, ә без - Муса шәкертләре. 29 Без Алланъщ Муса
белән сөйләшкәнен беләбез, э бу Гайсә дигән Кешенең кайдан икәнен дә
белмибез, - диделәр. 30 Күрә башлаган кеше аларга җавап биреп: - Шунысы
гаҗәп тә: сез Аның кайдан икәнен белмисез, ә Ул минем күзләремне ачты! 31 Без
Алланың гөнаһлыларны тыңламавын беләбез, әмма Аллага табынучыны һәм
Аның ихтыярын башкаручыны Ул тьщлый. 32 Кемнең дә булса тумьпптан сукыр
кешенең күзләрен ачуы турында гомердә дә ишетелгәне юк. 33 Ул Кеше Алладан
булмаса, һичнәрсә булдыра алмас иде, - дип әйтте. 34 - Башыңнан аягыңа тикле
гөнаһта тугансың, синме безне өйрәтәсең? - дип, алар аны куып чыгардылар.

## Рухи сукырлык

35 Гайсэ, аны куып чыгарганнарын ишеткәч, аны табып: - Син Адәм Улына иман
китерәсеңме? - дип сорады. 36 Ул: - Әфэндем, мин Аңа иман китерү өчен Аның
кем икәнен эйт миңа, - дип җавап бирде. 37 Гайсэ эйтте: - Син Аны күрдең. Хәзер
синең белән Ул сөйләшә. 38 Ул исэ: - Раббым, мин иман китерәм! - дип, җиргә
егылып, Аңа табынды. 39 Гайсә: - Мин бу дөньяга күрми торганнар күрсеннэр, ә
күрэ торганнар сукырайсыннар дип, хөкем итү өчен килдем, - дип әйтте. 40 Аның
янында булган кайбер фарисейләр, моны ишеткәч, Аңа: - Эллә без дэ сукырмы? -
диделэр. 41 - Сез сукыр булсагыз, гөнаһыгыз өчен гаепле булмас идегез; ә сез,
күрәбез, дигәнлектән гөнаһыгыз үзегездә кала, - дип эйтте Гайсэ.

## Гайсэ - яхшы көтүче

10:1 - Сезгә чын доресен әйтәм: кем сарык утарына капкадан түгел, бэлки башка
юл белэн керә, ул - карак һәм юлбасар. 2 Ә капкадан керүче сарыкларга көтүче
була: 3 Аңа сакчы капка ача, сарыклар аның тавышын ишетәләр һәм ул,
сарыкларын исемнәре белән чакырып, аларны алып чыга. 4 Үзенең бар
сарыкларын алып чыкканнан соң, ул алар алдыннан бара; ә сарыклар аның
артыннан баралар, чөнки аның тавышын таныйлар. 5 Алар, чит кешенең тавышын
танымаганга күрә, аның артыннан бармыйлар, э аннан качып китәләр. 6 Гайсә
аларга бу мэсэлне сөйләде, лэкин алар Аның нәрсә хакында сейләгәнен
аңламадылар. 7 Шулай итеп, Гайсә аларга янә: - Сезгә чын дөресен эйтэм: Мин -
сарыкларга капка. 8 Миннән алда килгәннәрнең барысы да карак һәм юлбасар
иделәр, ләкин сарыклар аларны тыңламадылар. 9 Мин - капка. Минем аша керүче
котылачак, керепчыгып йериячәк һәм кетүлек табачак. 10 Карак ул урлау, үтерү
һәм һәлак итү ечен генә килә. Мин исә, аларда тормыш булсын, мул тормыш
булсын дип килдем. 11 Мин - яхшы кетүче: яхшы кетүче сарыклары ечен җанын
бирэ. 12-13 Э ялланган кетүче - чын кетүче түгел ул. Сарыклар үзенеке
булмаганга күрә, ул алар турында кайгыртмый: бүренең килгэнен күреп,
сарыкларны ташлап качып китэ, бүре сарыкларга һөҗүм итеп аларны таратып
бетерэ. 14-15 Мин - яхшы көтүче. Ата Мине, Мин Атаны таныган кебек, Мин
үземнекеләрне таныйм, алар Мине таныйлар. Мин сарыкларым өчен
тормышымны бирэм. 16 Минем бу утардан булмаган башка сарыкларым да бар.
Мин аларны да алып килергә тиешмен. Алар Минем тавышымны ишетэчәкләр
һәм бер көтү, бер көтүче булачак. 17 Ата Мине шуның өчен ярата: Мин
тормышымны, аны яңадан алу өчен бирәм. 18 Аны Миннән беркем дэ алмый,
бэлки Мин аны Үзем бирәм: аны бирергә дә, кире алырга да вәкаләтем бар.
Мондый боерыкны Мин Атамнан кабул итеп алдым. 19 Бу сүзлэр нэтиҗэсендэ
яһүдлэр арасында янә бэхәс чыкты. 20 Аларның күбесе: - Аңарда җен бар, Ул
акылсыз. Сез ни өчен Аны тыңлыйсыз? - дип эйттелэр. 21 Башкалары исә: - Бу
җенле кеше сүзләре түгел, җен сукырның күзләрен ача аламы эллэ? - диделэр.

## Яһүдләр Гайсәне кабул итмиләр

22 Кыш җиткәч, Иерусалимда Яңару бәйрәме вакытында, 23 Гайсә Алла
Йортында Сөләйманның баганалы залында йөргән вакытта, 24 яһүдләр, Аның
тирәсенә җыелып, Аңа: - Син безне интектергеч билгесезлектә озак тотарсыщмы?
Син Мәсих булсаң, безгә ачык итеп әйт, - диделәр. 25 Гайсә аларга болай дип
җавап бирде: - Мин сезгә әйттем,ә сез ышанмыйсыз. Мин Атам исеменнән
эшләгән эшләр Минем хакта шаһәдәт бирәләр. 26 Әмма сез иман китермисез,
чөнки сез Минем сарыкларымнан түгел. 27 Минем сарыкларым Минем
тавышымны ишетәләр, Мин дә аларны таныйм, һәм алар Минем артымнан
баралар. 28 Мин аларга мәңгелек тормыш бирәм. Алар һичкайчан да һәлак
булмаячаклар һәм аларны беркем дә Минем кулымнан тартып ала алмаячак. 29
Аларны Миңа биргән Атам һәммәсеннән дә бөек. Минем Атамньщ кульшнан
аларны тартып алырга беркемнең дә хәленнән килмәячәк. 30 Мин һәм Ата - бер.
31 Шуннан соң яһүдләр, Аны үтерергә теләп, тагын кулларына ташлар алдылар.
32 Гайсә аларга: - Мин сезгә Атам исеменнән күп яхшы эшләр күрсәттем,
шуларның кайсысы өчен сез Мине таш атып бәреп үтерергә телисез? - дип әйтте.
33 Яһүдләр Аңа: - Без Сине яхшы эшләрең өчен түгел, бәлки Алланы хөрмәт
итмичә, Аңа каршы көфер сүз сөйләвең, Үзең кеше була торып, Үзеңне Алла дип
әйтүең өчен үтерергә телибез, - дип җавап бирделәр. 34 Гайсә аларга: - Алланың
«"Сез - илаһлар", - дидем Мин» дип әйткән сүзләре сезнең кануныгызда язылган
түгелме? 35 Ул Алла сүзе бирелгәннәрне илаһлар дип атаган икән, - ә Изге Язма
бозыла алмый, - 36 ничек сез, Ата изге эшкә аерып дөньяга җибәргән Затка, Мин
«Мин - Алла Улы», дип әйтеп тә, «Көфер сөйлисең», дисез? 37 Мин Атамның
эшләрен башкармыйм икән, Миңа ышанмагыз. 38 Ә инде башкарам икән, Минем
Үземә ьпнанмасагыз да, Атамның Миндә, Минем Атамда икәнлекне белү һәм
аңлау өчен, эшләремә ышаньпыз, - дип әйтте. 39 Шунда Аны тагьо кулга алырга
тырыштылар, әмма Ул алардан качып китте. 40 Шуннан соң, Гайсә тагын
Иорданның аръягына, элек Яхъя чумдырган урынга китте һәм шунда кадцы.41
Күпләр Аның янына килделәр һәм бер-берсенә: - Яхъя һичбер могҗизалы галәмәт
күрсәтмәде, әмма Яхъяның Аның турында әйткәннәре һәммәсе дә дөрес булды, -
диделәр. 42 һәм анда күпләр Аңа иман китерделәр.

## Гайсәнең Лазарны улгәннән соң терелтеп торгызуы

11:1 Мәрьям белән аның апасы Мәритә яшәгән Бетани авылында Лазар исемле
бер кеше авырый иде. 2 Мәрьям - Ходайның аякларын ислемай белән майлап,
чәче белән сөрткән хатынкыз, ә авыручы Лазар - аның абыйсы иде. 3 Кыз туганнар
Гайсәгә: - Раббым! Син яраткан Лазар авырый, - дип хәбәр җибәрделәр. 4 Гайсә
моны ишеткәч: - Бу авыру үлемгә түтел, бәлки Алла даны хакына һәм бу авыру
аша Алла Улы данлансын өчен, - диде. 5 Гайсә Мәритәне, аның сеңлесен һәм
Лазарны ярата иде, 6 әмма Ул Лазарның авыру икәнен ишеткәч тә булган
урынында тагын ике көнгә тоткарланды. 7 Шуннан соң шәкертләренә: - Яңадан

Яһүдиягә барыйк, - диде. 8 Шәкертлләре Аңа: - Остаз! Эле күптән түтел генә
яһүдләр Сине таш атып бәреп үтерергә йөргәннәр иде, Син тагын шунда
барасыңмы? - диделәр. 9 Гайсә җавап бирде: - Көн яктылыгы унике сәгать
түтелме соң? Көндез йөрүче абьшмый, чөнки ул бу дөньяның яктысин күрә. 10 Ә
төнлә йөрүче абына, чөнки анда яктылык юк. 11 Шуннан соң Гайсә сүзен дәвам
итте: - Безнең дустыбыз Лазар йоклап киткән, Мин аны уятырга барам. 12 Аның
шәкертлләре: - Раббым! Йоклап киткән булса, савыгыр, - диделәр. 13 Гайсә аның
үлгәнлеге хакында әйтте, ә алар исә гадәттәге йокы турында сөйли дип
уйладылар. 14 Шуңа күрә Гайсә аларга ачык итеп: - Лазар үлде. 15 Сез иман
китерсен дип анда булмавыма сезнең өчен шатланам. Әйдә, аның янына барыйк,
- диде. 16 Игезәк кушаматлы Тома шәкертләргә: - Әйдәгез, киттек, Аның белән
бергә без дә үлик, - дип әйтте. 17 Гайсә, Бетанигә килеп җиткәч, Лазарньщ инде
дүрт көн буена кабердә ятуын ишетте. 18 Бетани исә Иерусалимга, унбиш стадия
чамасы гына иде. 19 Абыйлары өчен кайгыручы Мәритә белән Мәрьямне юатырга
байтак яһүдләр килгән иде. 20 Мэритэ, Гайсәнең килүе хакында ишеткәч, Аны
каршы алырга чыкты. Мәрьям исә өйдә калды. 21 Мәритә Гайсәгә әйтте: -
Раббым! Син монда булган булсаң, минем абыем үлмәгән булыр иде. 22 Эмма
хәзер дә беләм: Син Алладан нәрсә генә сорасаң да, Алла Сиңа бирәчәк. 23
Гайсә аңа: - Синең абыең үледән тереләчәк, - диде. 24 Мәритә Аңа әйтте: -
Кыямәт көнендә - терелү вакытында - аның тереләчәген белэм. 25 Гайсэ аңа: -
Мин - терелү һәм тормыш. Миңа иман китерүче кеше үлсә дә яшәячәк. 26 Яшәүче
һәм Миңа иман китерүче һәркем һичкайчан үлмәс. Син моңа ышанасыңмы? -
диде. 27 Мәритә Аңа: - Әйе, Раббым! Мин Синең дәньяга килергә тиеш булган
Алла Улы Мәсих икәнеңә ышанам, - диде. 28 Моны эйткәч, Мәритә китеп барды
һәм, сиздермичә тенә, сеңлесе Мәрьямне чакырып: - Остаз монда, Ул сине
чакыра, - диде. 29 Мәрьям, моны ишеткәч тә, тиз генә урыныннан торып, Гайсә
янына китте. 30 Ул вакытта Гайсә әле авылга кермичә, Мәритә белән очрашкан
урында тора иде. 31 Мәрьям белән бергә булган юатучы яһүдләр, аның җәһәт
кенә торып чыгып китүен күрделәр дә, елар өчен кабер янына китте дип уйлап,
аның артыннан киттеләр. 32 Мәрьям исә, Гайсә торган урынга килеп җиткәч, Аны
күреп: - Раббым! Син монда булган булсаң, минем абыем үлмәгән булыр иде, -
дип, Аның аякларына егылды. 33 Гайсә, Мәрьямнең һәм аның белән килгән
яһүдләрнең елауларын күреп, Үзе дә борчылып көенде һәм: 34 - Сез аны кайда
күмдегез? - дип сорады. Алар Аңа: - Әйдә, барыйк, Раббым! Үзең күрерсең, -
диделәр. 35 Гайсә елады. 36 Моны күреп яһүдләр: - Карагыз әле, Ул Лазарны
ничек яраткан икән! - диештеләр. 37 Ә кайберләре: - Ул сукырның күзләрен ачкан
икән, ник соң Лазарны да үлемнән алып калу өчен берәр нәрсә эшли алмаган? -
диделәр. 38 Гайсә тагын да ныграк көенгән хәлдә кабер янына килде. Кабер
мэгарэ булып, аңа керү юлы таш белән бастырып куелган иде. 39 Гайсә: - Ташны
читкә алып куегыз, - диде. Үлгән кешенең сеңлесе Мэритэ Аңа: - Раббым! Ул инде
ислэнгэн, чөнки ул үлгәннән соң дүрт көн үтте, - диде. 40 Гайсэ аңа: - Мин Сиңа,
«Әгәр иман китерсәң, Алланың даньш күрәчәксең», дип әйтмәдемме? - диде. 41
Мэгарэ авызыннан ташны алып куйдылар. Гайсэ исә, югарыга карап: - Атам! Сиңа

Мине ишеткэнең өчен рэхмәт әйтәм. 42 Тавышымны һәрвакыт ишетүеңне беләм,
лэкин бу сүзләремне монда басып торучы кешеләр өчен, Мине Синең
җибәргәнеңә ышансыннар өчен эйтэм, - диде. 43 Моны әйткәннән соң Ул көчле
тавыш белән: - Лазар! Чык! - диде. 44 Шул вакыт үлгән кеше килеп чыкты. Аның
куллары һәм аяклары кәфен белән уралган, йөзе яулык белән капланган иде.
Гайсэ: - Чишегез аны, йөрсен, - диде.

## Фарисейләр Гайсәне үтерергә ниятлиләр

45 Мәрьям янына килгән яһүдләрнең күбесе, Гайсэ эшләгән эшләрне күреп, Аңа
иман китерделәр. 46 Э кайберләре, фарисейлэр янына барып, аларга I айсә
эшләгән эшләр турында сөйләделәр. 47 Шунда баш руханилар һәм фарисейләр
киңәшмә җыйдылар. Алар: - Безгә нәрсә эшләргә, - диештеләр. - Бу кеше күп
галәмэтләр күрсәтә. 48 Аны шул кее калдырсак, һәммәсе Аңа иман китерәчәк,
һәм римлылар килеп, безнең җиребезне дә, халкыбызны да басып алачаклар. 49
Аларның берсе, ул елны иң баш рухани булган Каяфас, аларга: - Сез бернэрсэ дэ
белмисез! 50 Бөтен халык һэлак булуга караганда, халык ечен бер кешенең үлүе -
сезнең өчен хәерлерәк. Сез шуны аңламыйсыз, - диде. 51-52 Ул моны үзеннэн
сөйләмәде, бэлки, ул елның иң баш рухание буларак, Гайсәнең халык өчен, халык
ечен генә дә түгел, бэлки таралган Алла балаларын бергә җыю очен дә үләчэген
алдан әйтеп бирде. 53 Шул көннән соң алар Аны үтерергә ниятләделәр. 54 Шуңа
күрә Гайсә инде яһүдләр арасында ачыктан-ачык йөрмәде. Ул аннан чүл
янындагы бер өлкәгә, Әфрәим дигән шәһәргә китте һәм Үзенең шәкертләре белән
шунда калды. 55 Яһүдләрнең Коткарылу бәйрәме якынлашканда, бәйрәм
алдыннан пакьләнергә дип, Иерусалимга илнең төрле почмакларыннан күп халык
килде. 56 Халык Гайсәне эзләде. Алар Алла Йортында бер-берсенә: - Сез ничек
уйлыйсыз? Ул бәйрәмгә килерме икән? - диештеләр. 57 Баш руханилар һәм
фарисейләр исә, Гайсәне тотып алу өчен, Аның кайда икәнлеген белгән кешеләр
безгә килеп әйтергә тиешләр, дип эмер бирделәр.

## Гайсэне Бетанидэ майлау

12:1 Гайсә, Коткарылу бәйрәменә алты көн кала, Бетани авылына килде. Ул
авылда Гайсә үледән терелткән Лазар яши иде. 2 Анда Гайсэ хөрмэтенә аш
мэҗлесе җыйдылар, Мэритэ хезмәт күрсәтеп йөрде, э Лазар Гайсә белән бергә
табын янында утыра иде. 3 Мэрьям, бер кадак нардтан ясалган бик кыйммәтле
саф ислемай алып, Гайсәнең аякларын майлады да үзенең чәче белэн сөртте. Өй
эче ислемайның хуш исе белән тулды. 4 Шунда Гайсәнең шәкертләреннән берсе -
Аңа хыянәт итәчәк Яһүд Искариот: 5 - Ни өчен бу ислемайны өч йөз динарга сатып
фәкыйрьләргә бүлеп бирмәскә иде? - диде. 6 Ул моны һич тә фәкыйрьләр
хакында кайгыртып түгел, бәлки карак булганы өчен әйтте. Уртак акча янчыгын
йөртү аның вазифасында иде. Ул үзенә аннан акча ала торган иде. 7 Гайсэ моңа
җавап бирде: - Мәрьямгэ тимэ, ул бу эшне Мине күмү көненә саклады, 8 чөнки

фэкыйрьлэр һэрвакыт сезнең белән булырлар, э Мин сезнең белэн һэрвакыт
бергә булмам. 9 Шул вакытта күп яһүдләр Гайсэнең Бетанидә икэнлеген белеп,
шунда килделэр. Алар Гайсэ өчен генэ түгел, Ул терелткэн Лазарны күрү өчен дә
килгэннэр иде. 10 Шунлыктан баш руханилар Лазарны да үтерергэ карар
чыгардылар, 11 чөнки аның аркасында, күп яһүдлэр Гайсә янына килеп, Аңа иман
китерделэр.

## Гайсэ тантана белэн Иерусалимга керэ

12 Икенче көнне бэйрэмгә килгэн халык арасында: «Гайсэ Иерусалимга килэ
икэн», - дигэн хэбэр таралды. 13 Алар, хөрмэ ботаклары тотып, Гайсәне
каршыларга чыктылар һэм аңа: «Осанна! Ходай исеме белэн Килүче һэм Исраил
Патшасы мөбарэк булсын!» - дип кычкырдылар. 14 Гайсэ исэ, бер ишәк табып,
аңа атланды һэм Изге Язмада язылганча булды: 15 «Сион кызы, курыкма! Менә,
яшь ишэккэ атланып, синең Патшаң килэ». 16 Аның шәкертләре ул вакытта моны
аңламадылар, ә инде Гайсэ данлы ителгэннэн соң Аның хакында шулай язылган
булуын һэм Аңа нәкъ шулай эшләүләрен хэтерләренэ төшерделәр. 17 Элек Аның
белән бергэ булган кешеләр Аның Лазарны кабердән чакырып чыгарып, үледән
терелтүенә шаһәдәт бирделәр. 18 Халык Аны каршыларга чыкты, чөнки алар
Аның шундый могҗизалы галәмәт кылганын ишеткәннәр иде. 19 Фарисейләр исә,
үзара: - Күрәсезме, безгэ бернәрсә дэ ярдәм итми. Бөтен дөнья Аның артыннан
бара, - диделәр.

## Гайсэ Үзенең үлэчэген белгертеп эйтэ

20 Бэйрәмдә Аллага табыну өчен килүчелэр арасында берничә грек та бар иде.
21 Алар Галилеядэге Бетсайдтан булган Филип янына килеп, аннан: - Әфәндем!
Без Гайсәне күрергэ телибез, - дип үтенделәр. 22 Филип бу турыда Эндригэ эйтте,
аннары алар икәүләп бу үтенечне Гайсәгә сөйләделәр. 23 Гайсә аларга
җавабында: - Адэм Улының данлы ителү вакыты җитте, - диде. 24 - Сезгә чын
дөресен эйтэм: җиргэ төшкэн бодай бөртеге үлмәсэ, шул килеш калыр, ә үлсә,
зур уңыш китерер. 25 Үзенең җанын яратучы аны һэлак итәчәк, ә бу дөньяда үз
җанына нәфрәт белән караучы аны мәңгелек тормыш өчен саклаячак. 26 Кем
Миңа хезмэт итә, ул Миңа иярсен. Мин кайда булсам, Минем хезмэтчем дә шунда
булыр. Миңа хезмэт итүчегә Атам ихтирам күрсэтер. 27 Күңелем Минем хэзер
борчулы. Нәрсә әйтим? «Атам! Мине бу сэгатьтэн коткар!» - дипме? Лэкин шушы
сэгатькә Мин моның өчен килдем дә. 28 Атам! Исемеңне данла. Шул вакыт
күктэн: - Мин данладым һэм данлаячакмын, - дигэн аваз килде. 29 Шунда торган
һэм моны ишеткэн халык: - Күк күкрэде, - диде. Кайберләре исэ: - Аңа фәрештэ
сөйлэде, - диделэр. 30 Моңа каршы Гайсэ: - Бу аваз Минем өчен түгел, бәлки
сезнең өчен килде. 31 Бу дөнья хэзер хөкем ителә, хәзер бу дөньяның мирзасы
куылачак. 32 Мин җирдән күтәрелгәннән соң барлык кешеләрне Үземә
тартачакмын, - диде. 33 Ул моны Үзенең нинди үлем белэн үлэчэген белгертеп

әйтте. 34 Халык Аңа җавап бирде: - Без кануннан Мәсихнең мәңге яшәячәген ишеттек, э Син ничек, Адәм Улы күтәрелергә тиеш, дисең? Кем Ул - Адәм Улы? 35 Шунда Гайсә аларга: - Яктылык сезнең белән бераз вакыт булыр әле. Үзегезне караңгылык басмасын өчен яктылык бар чагында йөреп калыгыз, чөнки караңгыда йөрүче кая барганын белми. 36 Яктылык сезнең белән булган чакта яктылыкка иман китерегез, шул чакта сез яктылык балалары булачаксыз, - диде. Шушы сүзләрне әйткәннән соң Гайсә алар яныннан китеп яшеренде.

## Халыкның Гайсәгә иман китермәве

37 Ул халык адцында шулкадәр күп могҗизалы галәмәтләр күрсәтсә дә, алар Аңа иман китермәгәнгә күрә, 38 Исай пәйгамбәрнең: «Раббым! Безнең хәбәргә кем иман китерде? Ходайның кодрәте кемгә ачылды?» дигән сүзләре тормышка ашты. 39 Алар иман китерә алмадылар, чөнки Исай әйткәнчә: 40 «Ул аларның күзләрен күрмәс итте, йөрәкләрен таш кебек катырды; югыйсә алар күзләре белән күрерләр, йөрәкләре белән аңларлар, үзләрен савыктырыуны сорап Миңа мөрәҗәгать итәрләр иде». 41 Исай бу сүзләрне Гайсәнең данын күргәнгә күрә әйткән, ул шулай дип Аның турында сөйләгән. 42 Хәер, башлыкларның да күбесе Аңа иман китерде, ләкин фарисейләрнең аларны синагогадан аеруларыннан куркып, икърар итмәделәр, 43 чөнки Алла данына караганда кешеләр данын күбрәк яраттылар. 44 Гайсә исә көчле тавыш белән: - Миңа иман китерүче Минем Үземә түгел, бәлки Мине Җибәрүчегә иман китерә, - диде. 45 - Мине күрүче Мине Җибәрүчене күрә. 46 Мин, Миңа иман китерүче караңгылыкта калмасын дип, дөньяга яктылык булып килдем. 47 Кем дә булса Минем сүзләремне ишетеп тә үтәми икән, Мин аны хөкем итмим, чөнки Мин дөньяга хөкем итү өчен түгел, бәлки дөньяны коткару өчен килдем. 48 Мине кире кагып, сүзләремне кабул итмәүченең үз хөкемчесе бар: аны Мин әйткән сүз кыямәт көнендә хөкем итәчәк. 49 Мин Үземнән сөйләмәдем, бәлки Мине җибәргән Ата нәрсә сөйләргә, нәрсә әйтергә кирәклеге хакында Миңа әмер бирде. 50 Мин Аның әмере мәңгелек тормыш китерүен беләм. Шулай итеп, Мин һәр сүзне Миңа Атам әйткәнчә сейлим.

## Гайсә шәкертләренең аякларын юа

13:1 Коткарылу бәйрәме алдыннан Гайсә, Үзенең бу дөньядан Ата хозурына китү сәгате җиткәнен белеп, дөньяда булган үзенекеләрен ничек яраткан булса, аларны соңгы чиккә кадәр шулай яратуын эш белән күрсәтте. 2 Иблис Симон Искариот улы Яһүднең күңеленә Гайсәгә хыянәт итү фикерен салганнан соң, Гайсә шәкертләре белән кичке аш ашаган вакытта, 3 Атаның һәрнәрсәне Аның кулына биргәнен һәм Үзенең Алладан килеп Алла янына китүен белеп, 4 урыныннан торды да, өс киемен салып, биленә сөлге урады. 5 һәм ләгәнгә су салып, шәкертләренең аякларын юа башлады, юган берсен билендәге сөлге белән сөртеп барды. 6 Нәүбәт Симон Питер янына җиткәч, Питер Аңа: - Раббым! Синме минем аякларымны юасың? - диде. 7 - Син әле хәзер Минем нәрсә

эшләвемне аңламыйсың, - дип җавап бирде Гайсә, - әмма соңыннан аңларсың. 8
- Син минем аякларымны һичкайчан юарга тиеш түгелсең, - диде Питер. - Синең
аякларыңны юмасам, Миндә синең өлешең булмас, - дип җавап бирде Гайсә. 9 -
Раббым! - диде Симон Питер. - Аякларымны гына түгел, кулларымны да,
башымны да юа күр. 10 - Юынган кешенең бөтен тәне чиста була. Шуңа күрә аның
аякларыннан башка бүтән җирен юу кирәк түгел. - диде Гайсә. - Сез чиста, эмма
барыгыз да түгел. 11 Үзенә кемнең хыянәт итәчәген белгәнгә күрә Ул: «Сезнең
барыгыз да чиста түгел», - диде. 12 Ул, шәкертләренең аякларын юып бетергәч,
киемен киеп, яңадан урынына барып утырды һәм аларга: - Минем нәрсә
эшләгәнемне аңлыйсызмы? 13 Сез Мине Остаз һәм Раббы дип атыйсыз. Сез
хаклы: Мин нәкъ Шулмын. 14 Шулай итеп, Мин, сезнең Ходаегыз һәм Остазыгыз,
сезнең аякларыгызны юганмын икән, сез дә бер-берегезнең аякларын юарга
тиешсез. 15 Мин сезгә эшләгән кебек, сез дә шулай эшләсен дип, сезгә үрнәк
күрсәттем. 16 Сезгә чын дөресен әйтәм: хезмәтче үзенең хуҗасыннан бөегрәк
түтел, җибәрелгән дә үзен җибәрүчедән бөек түгел. 17 Сез хәзер моны беләсез,
белгэнегезне үтисез икән, сез - бэхетле. 18 Мин барыгыз турында да сейләмим.
Кемнэрне сайлап алганымны беләм, лэкин Изге Язмада: «Минем белән бергә
икмәк ашаучы Миңа каршы үкчэсен күтэрде», - дип язылган сүзлэр тормышка
ашырга тиеш. 19 Ул эш булган вакытта сез Минем мәңге бар икәнемә иман
китерсен өчен, Мин сезгә бу сүзләр тормышка ашканчы ук сөйлим. 20Сезгә чын
дөресен эйтәм: Мин җибәргәнне кабул итүче Мине кабул итә; Мине кабул итүче
исә Мине Җибэрүчене кабул итә.

## Гайсэ хыянэтче Яһүдне фаш итэ

21 Моны сөйләгәннән соң Гайсэ борчылды һәм Ул шэкертләренэ шаһэдэт биреп:
- Сезгэ чын дөресен эйтэм: сезнең берегез Миңа хыянэт итэчәк, - диде. 22
Шэкертлэре исә, Аның кем хакында сөйләвен һич аңламыйча, бер-берсенә
караштылар. 23 Аларның берсе - Гайсэнең яраткан шәкерте - Аның күкрэгенэ
терэлеп диярлек утыра иде. 24 Симон Питер шул шэкерткэ, Гайсэнең кем хакында
сөйлэвен сорарга кушып, ишарә итте. 25 Теге шәкерт, Гайсэгә тагын да якынрак
килеп, Аннан: - Раббым, ул кем? - дип сорады. 26 Гайсэ җавап биреп: - Мин бер
сынык икмәкне кемгә манып бирсэм, ул - шул, - диде һэм, бер сынык икмэкне
манып, Симон Искариот улы Яһүдкэ бирде. 27 Шул сыныкны алганнан соң ук аңа
шайтан керде. Шунда Гайсэ Яһүдкэ: - Эшлисе эшеңне тизрэк эшлэ, - диде. 28
Эмма Гайсэнең аңа ни өчен шулай дип әйтүен анда утыручыларның берсе дә
аңламады. 29 Акча янчыгы Яһүдтэ булганлыктан, кайберәүлэр Гайсә аңа бэйрэм
өчен безгэ кирэк булган эйберлэрне сатып алырга, яки фэкыйрьлэргә нәрсэ дэ
булса бирергә кушкандыр дип уйладылар. 30 Яһүд, сыныкны алгач та, чыгып
китте. Төн иде.

## Яңа эмер бирэм: бер-берегезне яратыгыз

31 Ул чыгып киткәч, Гайсә әйтте: - Хәзер Адәм Улы данлы ителде һәм Аның аша
Алла данлы ителде. 32 Алла да Адәм Улын Үзендә данлы итәчәк, һәм Аның аша
Үзе данлы ителгәч үк, Аны данлы итәчәк. 33 Балаларым! Мин сезнең белән инде
озак булмам. Сез Мине эзләрсез. Яһүдләргә әйткән сүзләремне сезгә дә әйтәм:
Сез Мин китәчәк урынга килә алмассыз. 34 Сезгә яңа әмер бирәм: бер-берегезне
яратыгыз. Мин сезне яраткан кебек, сез дә бер-берегезне яратыгыз. 35
Бер-берегезне яратуыгыздан барысы да сезнең Минем шәкертләрем булуыгызны
белерләр. 36 Симон Питер Гайсәдән: - Раббым! Син кая китәсең? - дип сорады.
Гайсә аңа: - Мин китәчәк урынга Син хәзер ияреп бара алмыйсың, әмма соңыннан
киләчәксең, - дип җавап бирде. 37 - Раббым! Ни өчен мин Синең артыңнан хәзер
бара алмыйм? Мин Синең өчен җанымны бирергә дә әзер, - диде Аңа Питер. 38
Гайсә аңа: - Син Минем өчен җаныңны бирергә дә әзерме? Сиңа чын дересен
әйтәм: әтәч кычкырганчы, син Миннән өч тапкыр ваз кичәчәксең, - диде.

## Мин - юл, хакыйкатъ һәм тормыш

14:1 - Борчылмагыз! Аллага ышаныгыз һәм Миңа ышаныгыз. 2 Минем Атам
йортында торыр урын күп. Әгәр дә алай булмаса, Мин сезгә әйткән булыр идем.
Мин сезгә урын әзерләргә барам. 3 Барып урын әзерләгәч, сез дә Мин булган
урында булсын өчен, янә килеп, сезне Үз яныма алачакмын. 4 Мин бара торган
урынга сез юлны беләсез. 5 Тома Гайсәгә: - Раббым! Кая баруыңны белмибез,
шулай булгач, анда бару юлын каян белик инде? - диде. 6 Гайсә аңа: - Мин - юл,
хакыйкать һәм тормыш. Минем аркылы үтмичә, Атам янына беркем дә килә
алмас. 7 Мине беләсез икән, Минем Атамны да белерсез. Шушы вакыттан
башлап, сез Аны беләсез һәм Аны күрдегез, - дии әйтте. 8 - Раббым! Безгә Атаны
күрсәт һәм без канәгать булырбыз, - диде Аңа Филип. 9 - Филип, Мин никадәр
вакыт сезнең белән бергә булып та син Мине белмисеңме? - дип әйтте Гайсә. -
Мине күргән кеше, Атаны да күргән була. Ничек инде син: «Безгә Атаны күрсәт», -
дисең? 10 Минем Атада, Атаның Миндә икәнлегенә ышанмыйсыңмы? Сезгә
сөйләгән сүзләрне Мин Үземнән сөйләмим, ә Миндәге Ата Үзенең эшләрен
башкара. 11 Минем: «Мин Атада һәм Ата Миндә», - дигән сүзләремә ышаныгыз.
Мин әйткән сүзләргә ышанмыйсыз икән, эшләгән эшләрем аркылы ышаныгыз. 12
Сезгә чын дөресен әйтәм: Миңа иман китерүче Мин башкарган эшләрне һәм
аларга караганда да бөегрәк эшләрне башкарыр, чөнки Мин Атам янына барам.
13 Ата Улында данлы ителсен өчен, Минем исемемнән Атадан нәрсә генә
сорасагыз да, эшләрмен. 14 Минем исемемнән Миннән нәрсә сорасагыз да, Мин
аны эшләрмен.

## Гайсо вәгъдә шпкән Изге Рух

15 - Мине яратсагыз, Минем әмерләремне үтәрсез. 16 Мин Атадан сораячакмын,
һәм Ул сезгә бүтән Яклаучы бирәчәк, Ул Яклаучы мәңге сезнең белән булачак. 17
Ул Яклаучы - Хакыйкать Рухы. Дөнья Аны күрмәгәнгә һәм белмәгәнгә күрә кабул

итэ алмый, ә сез Аны белэсез, ченки Ул сездэ калачак. 18 Сезне ятим
калдырмаячакмын, чөнки сезнең янга килэм. 19 Денья Мине бераздан күрмэячэк,
э сез күрәчэксез. Мин яшим, сез дә яшәячәксез. 20 Ул көнне сез Минем - Атамда,
сезнең - Миндә һәм Минем сездә икәнлегемне беләчәксез. 21 Минем
эмерлэремне кабул итеп, аларны үтәгән кеше Мине ярата. Мине яраткан кешене
Атам да яратыр, Мин дә яратырмын һәм аңа Үземне күрсәтермен. 22 Яһүд (Яһүд
Искариот түгел) Аннан: - Раббым! Ни өчен Син Үзеңне дөньяга түтел, ә безгә
күрсэтергә телисең? - дип сорады. 23 Гайсә аңа җавабында: - Мине яратучы
Минем сүзләремне тотар. Атам аны яратыр һәм Без аның янына килеп, аның
белэн бергә ящәрбез. 24 Мине яратмаучы Минем сүзләремне тотмый. Сез ишетә
торган сүз Миннән түгел, бэлки Мине җибәргән Атадан, - дип эйтте. 25 - Мин сезгэ
боларны сезнең белән бергә булганда ук әйттем. 26 Э Минем исемемнән Ата
җибәрэчэк Яклаучы - Изге Рух - сезне һәрнәрсәгә өйрэтәчәк һәм Мин сезгә
сейләгәннәрнең һәммәсен дә хәтерегезгә тешерәчәк. 27 Сезгэ тынычлык
калдырам, Үземнең тынычлыгымны сезгэ бирәм, әмма сезгә Минем биргәнем
дәнья биргән кебек түгел. Күңелегез борчылмасын һәм курыкмасын. 28 Сез
Минем: «Сездән китэм һәм сезгэ килэчэкмен», - дигэнемне ишеттегез. Сез Мине
яратсагыз, Атам янына баруыма куаныр идегез, чөнки Минем Атам Миннән
бөегрәк. 29 Мин сезгә бу сүзләрне ул хәл тормышка ашканда сез ышансын өчен
хәзер сөйлэдем. 30 Сезнең белән күп сөйлэшмәм инде, чөнки бу дөньяның
мирзасы килә. Аның Миндә һичнәрсәсе юк. 31 Эмма дөнья белсен: Мин Атаны
яратам һэм, Ата Миңа нинди әмер биргән булса, Мин шуны башкарам. Торыгыз,
моннан китик, - диде.

## Гайсэ - чын йөзем чыбыгы

15:1 - Мин - чын йәзем чыбыгы, ә Минем Атам - йәзем үстерүче. 2 Ул Миндәге
җимеш бирми торган һәр ботакны кисеп ташлый һәм җимеш бирэ торган һәр
ботакны күбрэк җимеш бирсен дип чистарта. 3 Минем сезгэ сөйләгән сүзем аша
сез инде чистартылдыгыз. 4 Миндэ торыгыз, һәм Мин сездә торырмын. Йезем
чыбыгында булмаган ботак үзеннән үзе җимеш бирә алмаган кебек, Миндэ
тормасагыз, сез дэ бирә алмассыз. 5 Мин - йөзем чыбыгы, э сез - ботаклар. Кем
Миндә торса һэм Мин аңарда торсам - ул күп җимеш бирер, чәнки Миннэн башка
бернәрсә дә эшли алмассыз. 6 Кем Миндэ тормаса, ботак кебек читкә ташланыр
һэм корып бетэр, ә андый ботакларны җыеп утка ташлыйлар һэм алар яналар. 7
Сез Миндә торсагыз һэм Минем сүзлэрем сездэ торса, ул чакта теләгән
нәрсэгезне сорагыз, һэм сезгә бирелер. 8 Күп җимеш китереп сез Минем шэкер
глэрем булырсыз, һэм моның белэн Минем Атам данланыр. 9 Атам Мине яраткан
кебек, Мин дә сезне яратам. Минем мәхәббэтемдэ горыгыз. 10 Мин Атамның
эмерлэрен үтәп, Аның мохәббәтендә горам, һэм сез дә, Минем эмерлэремне
үтэсэгез, Минем мәхәббәтемдә калырсыз. 11 Минем куанычым сездә булсын һэм
сезнең куанычыгыз тулы булсын дии, Мин боларны сезгә сөйләдем. 12 Минем
әмерем шушы: Мин сезне яраткан кебек, сез дә бер-берегезне яратыгыз. 13

Дусларың өчен үзенең җанын биргән кешенең яратуыннан да бөек ярату юк. 14
Минем әмерләремне үтәсәгез, сез - Минем дусларым. 15 Мин инде сезне
хезмәтчеләрем дип атамыйм, чөнки хезмәтче үз хуҗасының нәрсә эшләвен
белми, ә Мин сезне дусларым дип атадым, чөнки Атамнан ишеткәннәремнең
һәммәсен сезгә белдердем. 16 Мине сез сайламадыгыз, бәлки Мин сезне
сайладым: Сез барып җимеш бирегез һәм җимешегез даими булсын дип, сезне
билгеләп куйдым. Шулай итеп, Минем исемемнән Атадан нәрсә генә сорасагыз
да, Ул аны сезгә бирәчәк. 17 Минем сезгә әмерем шул: бер-берегезне яратыгыз.

## Дөньяның нәфрәте

18 - Дөнья сезгә нәфрәт итә икән, исегездә тотыгыз: ул сездән элек Миңа нәфрәт
итте. 19 Сез дөньяныкы булсагыз, дөнья сезне үзенекеләре итеп яратыр иде.
Ләкин сез дөньядан түгел, бәлки Мин сезне дөньядан сайлап алдым, дөнья сезгә
шуңа күрә нәфрәт итә. 20 Минем: «Хезмәтче үзенең хуҗасыннан өстен түгел», -
дигән сүзләремне хәтерләгез. Мине эзәрлекләгәннәр икән, сезне дә
эзәрлекләрләр. Минем сүземне тотканнар икән, сезнекен дә готарлар. 21 Алар
боларның барысын да сез Минеке бултанлыктан эшләрләр, чөнки Мине
Җибәрүчене белмиләр. 22 Мин килеп аларга сөйләмәгән булсам, аларның
гөнаһта гаепләре булмас иде, ә хәзер гөнаһларын акларлык чаралары юк. 23
Миңа нәфрәт итүче Минем Атама да нәфрәт итә. 24 Мин башка беркем дә
эшләмәгән эшләрне алар арасында күрсәтмәгән булсам, аларның генаһта
гаепләре булмас иде; ә хәзер күрделәр һәм Миңа да, Атама да нәфрәтләнделәр.
25 Эмма аларның канунында: «Алар Миңа бер сәбәпсезгә нәфрәтләнделәр», -
дип язылган сүзләр тормышка ашсын өчен шулай булды. 26 Мин Атадан сезгә
Яклаучы җибәрәчәкмен. Ул - Атадан чыккан Хакыйкать Рухы - килгәч, Минем хакта
шаһәдәт бирәчәк. 27 Сез дә шаһәдәт бирерсез, чөнки сез баштан ук Минем белән
булдыгыз.

16:1 - Мин боларны сез вәсвәсәгә бирелмәсен өчен сөйләдем. 2 Сезне
синагогалардан аерырлар. Хәтта шундый вакыт килер: ул вакытта сезне үтерүче
һәркем Аллага шуның белән хезмәт итәм дип уйлар. 3 һәм шулай эшләрләр,
чөнки алар Атаны да, Мине дә белмәделәр. 4 Мин моны сезгә шуның өчен
әйттем: ул вакыт җиткәч, сез ул хакта сөйләгәнемне исегезгә төшерерсез. Мин
боларны сезгә башта ук сөйләмәдем, чөнки сезнең белән бергә булдым.

## Яклаучының килүе

5 Ә хәзер Мин Үземне Җибәрүче янына барам, һәм сезнең берегез дә Миннән:
«Кая барасың?» - дип сорамый. 6 Мин боларны сезгә сөйләгәнгә күрә, сезнең
күңелегез кайгы белән тулды. 7 Эмма Мин сезгә дөресен сөйлим: Минем китүем
сезнең өчен хәерлерәк; чөнки, Мин китмәсәм, сезгә Яклаучы килмәячәк; ә китсәм,
Мин Аны сезгә җибәрәчәкмен. 8 Ул килгәч, гөнаһка, тәкъвалыкка һәм хөкемгә

карата дөньяны фаш итәчәк: 9 гөнаһ -аларның Миңа иман китермәүләрендә; 10 тәкъвалык - Минем Атам янына баруымда һәм сезнең инде Мине бүтән күрмәвегездә; 11 хөкем - бу дөньяның мирзасы инде хөкем ителүдә. 12 Сезгә сөйлисе сүзләрем бик күп, әмма сез аларны хәзер кабул итә алмассыз. 13 Ул - Хакыйкать Рухы - килгәч, сезгә тулы хакыйкатькә юл күрсәтеп торачак. Ул сезгә Үзеннән түгел, бәлки ишеткәнен сөйләячәк һәм булачак хәлләрне белдерәчәк. 14 Ул, Минекеннән алып сөйләп, Мине данлаячак. 15 Атаныкы булган барлык нәрсәләр - Минеке; Мин шуңа күрә: «Минекеннән алып сезгә белдерәчәк», - дидем.

## Шәкертләрнең кайгысы шатлыкка әйләнер

16 - Сез Мине бераздан күрмәячәксез инде, һәм янә бераздан Мине күрәчәксез. 17 Шуннан соң Аның кайбер шәкертләре бер-берсенә: - «Бераздан сез Мине күрмәячәксез, һәм янә бераздан Мине күрәчәксез», һәм: «Мин Атам янына барам», - дип әйтүе нәрсәне аңлата икән? 18 «Бераздан» дигәне нәрсә икән? Аның нәрсә сөйләгәнен аңламыйбыз! - диештеләр. 19 Гайсә, Үзеннән нәрсә турында сорарга теләгәннәрен белеп, аларга: - Сез Минем: «Сез Мине бераздан күрмәячәксез, һәм янә бераздан Мине күрәчәксез», - дигән сүзләрем хакында бер-берегездән сорашасызмы? 20 Сезгә чын дөресен әйтәм: сез еларсыз, үкереп еларсыз, ә дөнья шатланыр; сез кайгырырсыз, әмма кайгыгыз шатлыкка әйләнер. 21 Сәгате җиткәч, бала тудыручы хатын җәфа чигә, әмма баласын тудыргач, дөньяга кеше тудыру шатлыгыннан газаплануын хәтерләми. 22 Шуның кебек сез дә хәзер кайгырасыз; әмма Мин сезне тагын күрәчәкмен, һәм сезнең күңелегез куаначак, һәм куанычыгызны сездән беркем дә ала алмаячак. 23 Ул көнне сез Миннән бернәрсә турында да сорамассыз. Сезгә чын дәресен әйтәм: Минем исемемнән Атадан нәрсә генә сорасагыз да, Ул сезгә бирәчәк. 24 Моңарчы сез Минем исемемнән бернәрсә дә сорамадыгыз. Сорагыз һәм алырсыз, һәм сезнең куанычыгыз тулы булыр.

## Кыю булыгыз: Мин дөньяны җиңдем

25 Моңарчы Мин сезгә мәсәлләр белән сөйләдем; ләкин вакыт җитәр, Мин сезгә инде мәсәлләр белән сейләмәм, бәлки Ата хакында ачык итеп сөйләрмен. 26 Ул кенне сез Минем исемемнән сорарсыз. Мин: «сезнең әчен Атадан үтенермен», - димим, 27 чөнки сез Мине яратканга һәм Минем Алладан килгән булуыма ышанганга күрә, Ата Үзе сезне ярата. 28 Мин дөньяга Атадан килдем; һәм менә яңадан доньяны калдырып, Ата янына китәм. 29 Шәкертләре Аңа: - Менә хәзер Син мәсәлләр белән түгел, э ачык итеп сөйлисең. 30 Хәзер без Синең һәрнәрсәне белүеңне һәм хәтта Сиңа сорауны сүзләр белән әйтүнең кирәк тә түгеллеген күрәбез. Менә шуңа күрә без Синең Алладан килгән булуыңа ышанабыз, - диделәр. 31 Гайсә аларга җавап бирде: - Сез хәзер ышанасызмы? 32 Менә вакыт җитә һәм җитте дә инде: сез таралып, һәрберегез үз өйләренә китәчәк. Сез Мине

ялгыз кадцырачаксыз. Лэкин Мин ялгыз түгел, чөнки Ата Минем белән. 33 Мин
моны сезгә тынычлыгыгыз Миндә булуыгызда булсын дип сөйләдем. Дөньяда
кайгыларыгыз булыр, ләкин кыю булыгыз: Мин дөньяны җиңдем.

## Гайсэнең догасы

17:1 Гайсә бу сүзләрдән соң күккә күтәрелеп карап: - Атам! Вакыт җитте, - диде. -
Улың Сине данласын өчен, Улыңны данлы ит. 2 Син Аңа биргән кешеләрнең
барысына да Ул мәңгелек тормыш бирсен өчен, Аңа бөтен кешеләр өстеннән
хакимлек бирдең. 3 Сине, бердэнбер хак Алланы, һәм Син җибэргән Гайсә
Мәсихне белү - шул мәңгелек тормыштыр. 4 Мин, Син тапшырган эшләрне
башкарып чыгып, Сине җирдә данладым. 5 Хэзер Син, Атам, Үзеңнең яныңда
Мине данлы ит. Дөнья яратылганга кадәр Синең белән булган вакыттагы даным
белэн мине данлы ит. 6 Син дэньядан Миңа биргән кешелэргэ Синең исемеңне
ачып бирдем. Алар Синеке иде һәм Син аларны Миңа бирдең. Алар Синең
сүзеңне тоттылар һәм 7 хәзер алар Син Миңа биргән бар нәрсәнең Синнән
икэнлеген беләләр. 8 Чөнки Син Миңа эйткән сүзләрне аларга җиткердем, алар
кабул иттеләр. һәм Минем чынлап та Синнән килүемне танып, Мине Син
җибәргәнлеккә иман китерделәр. 9 Мин алар өчен үтенәм. Бөтен дөнья өчен
түгел, бәлки Син Миңа биргәннәр өчен үтенәм, чөнки алар Синеке. 10 Минем
бөтен нәрсәм Синеке, ә Синекеләр - Минеке. Мин алар аркылы данлы ителдем.
11 Мин инде дөньяда түгел, ә алар әле деньяда. Мин Синең яныңа барам. Изге
Атам! Без бер булган кебек, алар да бер булсыннар өчен, аларны Үзеңнең
исемеңдә, Син Миңа биргән исемеңдә саклап тор. 12 Алар белән бергә дөньяда
булганда, Мин аларны Синең исемеңдә - Синең Миңа биргән исемеңдэ саклап
тоттым. Мин аларны сакладым һәм Изге Язмада язылган сүзләр тормышка ашсын
өчен, һәлак булырга тиешлесеннән башка берсе дә югалмады. 13 Хэзер исә Мин
Синең яныңа барам. Мин бу сүзлэрне, аларда куанычым тулы булсын өчен,
дөньяда чакта сөйлим. 14 Мин аларга Синең сүзеңне җиткердем. Дәнья аларга
нәфрәтләнде, чөнки Мин дөньядан булмаган кебек, алар да дөньядан түгел. 15
Мин Синнэн аларны дөньядан алуыңны түгел, бэлки явызлыктан саклавыңны
үтенәм. 16 Мин дөньядан булмаган кебек, алар да дөньядан түгел. 17 Аларны Үз
хакыйкатеңцә изге ит. Синең сүзең - хакыйкать. 18 Син Мине дәньяга җибәргән
кебек, Мин дә аларны дөньяга җибэрдем. 19 Алар да хакыйкатьтә изге ителсеннәр
дип, Үземне алар хакына изге итәм. 20 Мин алар өчен генә түгел, бәлки аларның
сүзе аркылы Миңа иман китерүчеләр өчен дә үтенэм: 21 Бөтенесе бер булсын.
Атам, Син Миндә һәм Мин Синдә булган кебек, Синең Мине җибэргәнеңә дөнья
иман китерсен әчен, алар да Бездә булсыннар. 22 Миңа Син биргән данны аларга
җиткердем: Без бер булган кебек, алар да бер булсыннар. 23 Мин - аларда, Син -
Миндэ. Мине җибәргән булуыңны һәм Мине яраткан кебек аларны да яратуыңны
дөнья танысын өчен, алар тулысынча бер булсыннар. 24 Атам! Син Миңа биргән
кешелэрнең Мин булачак урында Минем белән бергә булуларын телим. Алар,
Син Мине дөнья яратылганга кадәр үк сөйгәнгә күрә, Миңа биргән данны

күрсеннәр иде. 25 Гадел Атам! Дөнья Сине белми, ә Мин Сине беләм, һәм алар
да Мине Син җибәргәнне беләләр. 26 Синең Миңа булган мәхәббәтең аларда да
булсын һәм Үзем дә аларда булыйм дип, Мин Синең исемеңне аларга белдердем
һәм белдерәчәкмен.

## Гайсәне кулга алу

18:1 Бу сүзләрне әйткәннән соң, Гайсә Үзенең шәкертләре белән Кедрон
инешенең аръягына чыгып, шундагы бакчага керде. 2 Гайсә Үзенең шәкертләре
белән еш кына шунда җыелганлыктан, ул урынны Аңа хыянәт итүче Яһүд тә белә
иде. 3 Яһүд, гаскәри төркем белән һәм баш руханилар һәм фарисейләр җибәргән
тәртип саклаучылар белән бергә шунда килде. Алар факеллар, якгырткычлар һәм
кораллар тоткан иделәр. 4 Гайсә исә, Үзе белән булачак һәр нәрсәне белеп,
алгарак чыкты һәм алардан: - Кемне эзлисез? - дип сорады. 5 Алар Аңа: -
Насаралы Гайсәне, - дип җавап бирделәр. Гайсә аларга: - Ул - Мин, - диде.
Хыянәт итүче Яһүд тә алар белән шунда тора иде. 6 Гайсә: «Ул - Мин», - дигәч,
алар артка чигенеп китеп, җиргә егылдылар. 7 Ул янә: - Кемне эзлисез? - дип
сорады. Алар: - Насаралы Гайсәне, - диделәр. 8 Гайсә җавап бирде: - Мин инде
сезгә: «Ул - Мин», - дип әйттем бит. Сез Мине эзлисез икән, минем белән булган
кешеләрне чыгарып җибәрегез. 9 Ул шулай дип: «Син Миңа биргәннәрнең берсен
дә югалтмадым», - дигән сүзләр тормышка ашсын өчен әйтте. 10 Симон Питернең
исә кылычы бар иде. Ул аны тартып чыгарды һәм иң баш руханиның хезмәтчесенә
селтәнеп, аның уң колагын чабып өзде. Ул хезмәтченең исеме Мәлик иде. 11
Әмма Гайсә Питергә: Кылычыңны кынына тыгып куй. Атам биргән касәне Мин
эчмәм дип уйлыйсыңмы әллә? - диде. 12 Гаскәриләр, аларның меңбашы һәм
яһүдләрнең тәргип саклаучылары Гайсәне тотып бәйләгәч, 13 башта шул елның
иң баш рухание булган Каяфасның каенатасы Әнәс янына алып бардылар. 14
Яһүдләргә: «Халык өчен бер кешенең үлүе хәерлерәк», - дип киңәш биргән кеше
шул Каяфас иде. 15 Симон Питер һәм тагын бер шәкерт Гайсә артыннан
бардылар. Бу шәкерт исә, иң баш рухани белән яхшы мөнәсәбәттә булганга күрә,
Гайсә белән иң баш руханиның ишегалдына керә алды. 16 Ә Питер тышта ишек
артында басып калды. Аннары иң баш рухани белән яхшы мөнәсәбәттә булган
теге шәкерт чыкты. Ишек саклаучы хезмәтче кызга әйтеп, Питерне эчкә алып
керде. 17 Шунда ишек саклаучы хезмәтче кыз Питергә: - Син дә Бу Кешенең
шәкертеме әллә? - дип сорагач, ул: - Юк, - диде. 18 Салкын булганлыктан
хезмәтчеләр һәм тәртип саклаучылар учак ягып җылынып торалар иде. Питер дә
алар белән бергә җылынып торды. 19 Иң баш рухани исә Гайсәдән Аның
шәкертләре һәм нәрсә өйрәтүе турында сорашты. 20 Гайсә аңа: - Мин дөньяга
ачык сөйләдем. һәрвакыт яһүдләр җыела торган синагогада һәм Алла Йортында
өйрәттем һәм яшеренеп һичнәрсә сөйләмәдем. 21 Нигә Миннән сорыйсың?
Минем сөйләгәннәремне ишеткәннәрдән сора. Минем нәрсә сөйләгәнемне алар
беләләр, - дип җавап бирде. 22 Гайсә шулай дигәч, Аның янында торган тәртип
саклаучыларның берсе Аның яңагына сугып: - Иң баш руханига Син шулай җавап

бирәсеңме? - диде. 23 Гайсә аңа: - Мин ялган сөйләгән булсам, ялган икәнен
исбат ит, ә дөресен сөйләгәнмен икән, нигә Миңа сугасың? - дип җавап бирде. 24
Энәс Аны, бәйләнгән хәлдә, иң баш рухани Каяфас янына җибәрде. 25 Симон
Питердән шунда җылынып торганда: - Син дә Аның шәкертләренең берсе
түгелме? - дип сорадылар. Ул: - Юк, - дип ваз кичте. 26 Иң баш рухани
хезмәтчеләренең берсе, колагын Питер чабып өзгән кешенең туганы, аңа: - Мин
сине Гайсә белән бергә бакчада күрдем түгелме соң? - диде. 27 Питер тагын ваз
кичте. Нәкъ шул вакыт әтәч кычкырды. 28 Гайсәне Каяфас яныннан идарәче
сараена алып килделәр. Бу хәл иртә белән булды. Алар Коткарылу бәйрәменең
ашын ашарга мөмкин булсын өчен, пакьләнүләре бозылмасын дип, идарәче
сараена кермәделәр. 29 Идарәче Пилат, алар янына чыгып: - Сез Бу Кешене
нәрсәдә гаеплисез? - дип сорады. 30 Алар аңа: - Ул җинаятьче булмаса, без Аны
сиңа тотып китермәгән булыр идек, - дип җавап бирделәр. 31 Пилат аларга: - Аны
кануныгыз буенча үзегез хөкем итегез, - диде. Яһүдләр аңа: - Безгә беркемне дә
үлемгә дучар итү хокукы бирелмәгән, - диделәр. 32 Бу Гайсәнең Үзенең нинди
үлем белән үләчәгенә ишарә итеп әйткән сүзе тормышка ашсын өчен эшләнде. 33
Шунда Пилат яңадан сараена керде һәм, Гайсәне чакыртып, Аннан: - Син
Яһүдләр Патшасымы? - дип сорады. 34 Гайсә аңа: - Син моны үзеңнән генә
әйтәсеңме, яки Минем хакта сиңа башкалар сөйләдеме? - диде. 35 Пилат әйтте: -
Әллә мин яһүдме? Сине миңа Синең халкың һәм баш руханилар тапшырдылар.
Син нәрсә эшләдең? 36 - Минем Патшалыгым бу дөньяныкы түгел. Әгәр
Патшалыгым бу дөньяныкы булса, хезмәтчеләрем яһүдләр кулына
тапшырылмавым өчен көрәшкән булырлар иде, әмма хәзер Минем Патшалыгым
моннан түгел, - дип җавап бирде Гайсә. 37 Пилат Аңа: - Димәк, Син Патша? -
диде. Гайсә җавап бирде: - Син Мине Патша дисең. Мин хакыйкать хакында
шаһәдәт бирү өчен тудым, Мин дөньяга да шуның өчен килдем. Минем
тавышымны хакыйкатьтән булган һәркем тыңлый. 38 Пилат Аңа: - Нәрсә ул -
хакыйкать? диде. Моны әйткәннән соң, ул яңадан яһүдләр янына чыгып: - Мин
Аңарда бернинди гаеп тапмыйм, - диде. 39 - Сезнең горефгадәтегез буенча,
Коткарылу бәйрәмендә мин сезгә бер тоткынны азат итәргә тиешмен. Яһүдләр
Патшасын азат итүемне телисезме? 40 Шунда барысы да: - Аны түгел,
Бараббасны чыгар! - дип кычкырдылар. Бараббас исә юлбасар иде.

## Үлем хөкеме

19:1 Шуннан соң, Пилат Гайсәне камчы белән суктырырга кушты. 2 Гаскәриләр,
Аның башына күгән агачы чыбыкларыннан таҗ үреп куйдылар, өстенә куе кызыл
төстәге япанча кидерделәр, 3 һәм берсе артыннан берсе Аның янына килеп: -
Яшәсен Яһүдләр Патшасы! - дип, яңакларына суктылар. 4 Пилат, янә чыгып,
халыкка әйтте: - Карагыз, Аңарда бернинди гаеп тапмавымны белдерү өчен Аны
сезнең янга чыгарам. 5 Башына чәнечкеле таҗ, өстенә япанча кигән Гайсә чыкты.
Пилат аларга: - Менә - Кеше! - диде. 6 Баш руханилар һәм тәртип саклаучылар,
Аны күргәч: - Хачка кадакла, кадакла Аны! - дип кычкырдылар. Пилат аларга: -

Аны үзегез кадаклагыз, чөнки мин Аңарда бернинди гаеп тапмыйм, - диде. 7
Яһүдләр аңа: - Безнең кануныбыз бар, канун буенча Ул үләргә тиеш, чөнки Ул
Үзен Алла Улы дип атый, - дип җавап бирделәр. 8 Бу сүзләрне ишеткәннән соң,
Пилат бигрәк тә куркуга төште, 9 һәм, янә сарайга кереп, Гайсәдән: - Син кайдан?
- дип сорады. Эмма Гайсә аңа җавап бирмәде. 10 Пилат Аңа: - Миңа җавап
бирәсең килмиме? Сине хачка кадаклатырга да, азат итәргә дә хокукым барлыгын
белмисеңме әллә? - диде. 11 Гайсә җавап бирде: - Сиңа югарыдан бирелмәгән
булса, Минем өстән һичбер хакимлегең булмас иде, шуңа күрә сиңа Мине
тапшыручының гөнаһы синекеннән зуррак. 12 Шуннан соң Пилат Аны азат итәргә
теләде. Яһүдләр исә: - Аны җибәрсәң, ул чакта син кайсарның дусты түгелсең;
үзенүзе патша итүче һәркем - кайсарның дошманы, - дип кычкырдылар. 13 Бу
сүзләрне ишеткәч, Пилат, Гайсәне чыгарып, «Таш басма» (яһүдчә Габбата) дип
аталган урындагы хакимлек урынына барып утырды. 14 Бу көн Коткарылу
бэйрэменэ хэзерлэнэ торган җомга көн, алтынчы сәгать иде. Пилат яһүдләргә: -
Менә сезнең Патшагыз! - диде. 15 Э алар: - Алып кит Аны, олаксын! Хачка
кадакла! - дип кычкырдылар. - Патшагызны кадаклыйммыни? - диде Пилат. Баш
руханилар: - Безнең Кайсардан башка патшабыз юк, - дип җавап бирделәр. 16
Ниһаять, ул Аны кадакларга дип, аларга тапшырды. Алар Гайсәне алып киттеләр.
Гайсәне хачка кадаклау 17 Үзенең хачын күгәреп, Гайсә «Баш Сөяге», ягъни
яһүдчә Голгота дип аталган урынга килеп җитте. 18 Аны һәм Аның белән бергә
гагын ике кешене, берсен бер ягына, икенчесен икенче ягына, э Гайсәне уртага
хачка кадакладылар. 19 Пилат кушканча язу язып, хач өстенә куйдылар. Ул язуда:
«Насаралы Гайсә - Яһүдләр Патшасы», - дип язылган иде. 20 Ул язуны күп
яһүдләр укыды, чөнки Гайсә хачка кадакланган урын шәһәргә якын иде, һәм ул
язу яһүдчә, грекча һәм латинча язылган иде. 21 Яһүдләрнең баш руханилары
Пилатка әйттеләр: - «Яһүдләр Патшасы», - дип түгел, бәлки, «Ул Үзен: Мин -
Яһүдләр Патшасы, - диде», - дип яз. 22 Пилат: - Мин нәрсә яздым, шул язылды
инде, - дип җавап бирде. 23 Гаскәриләр исә, Гайсәне хачка кадаклагач, Аның
киемнәрен алып һәр гаскәригә бер елеш итеп дүрткә бүлделәр һәм чапанын да
алдылар; чапан исә тегелмәгән, бәлки бербөтен тукыма иде. 24 Шулай итеп алар
бер-берсенә: - Моны ертмыйк, бәлки жирәбә салышыйк, кемгә чыгар, - диделәр.
Бу Изге Язмадагы: «Алар Минем киемнәремне бүлештеләр, күлмәгем өчен
жирәбә салыштылар», - дип язылган сүзләр тормышка ашсын өчен булды.
Гаскәриләр нәкъ шулай эшләделәр. 25 Гайсә кадакланган хач янында Аның
анасы, анасының сеңлесе, Килопас хатыны Мэрьям һәм Магдалалы Мэрьям
басып торалар иде. 26 Гайсә, Үзенең анасын һәм шунда ук торган сеекле
шәкертен күреп, анасына: - Ханым! Менә бу - синең улың, - диде. 27 Аннары
шәкерткә: - Менә бу - синең анаң! - дип әйтте. Шэкерт шуннан соң аны үз өенә
алды.

## Гайсәнең үлеме

28 Шуннан соң Гайсә, һәрнәрсәнең чынга ашканын белеп, һәм Изге Язмада

язылганнар тормышка ашсын дип: - Сусадым, - диде. 29 Шунда шәраб серкәсе
салынган савыт тора иде. Гаскәриләр, бер кисәк болытны серкәгә манчып, аны
иссоп ботагына элеп Аның авызына китерделәр. 30 Гайсә серкәне татыгач: -
Чынга ашты! - диде һәм, башын иеп, җан бирде. 31 Бу көн бәйрәм алдындагы
җомга көн булганлыктан, яһүдләр гәүдәләрне шимбә көнгә хачта калдырмас өчен
- чөнки ул шимбә бөек көн иде - Пилаттан аларның аякларын сындырып, аларны
алып ташлауны сорадылар. 32 Шуннан гаскәриләр килеп, Гайсә белән бергә
кадакланганнарның башта берсенең, аннан икенчесенең аякларын сындырдылар.
33 Әмма Гайсә янына килтәч, Аның инде үлгән булуын күрделәр һәм шуңа күрә
аякларын сындырмадылар, 34 ә бер гаскәри Аның кабыргасына сөңге белән
чәнчеде. Аннан кан белән су агып чыкты. 35 Бу хәлләрне күргән кеше шул хакта,
сез иман китерсен дип, шаһәдәт бирде. Аның шаһәдәте хак һәм ул хакыйкатьне
сөйләвен белә. 36 Чөнки бу хәл Изге Язмада: «Аның һичбер сөяге сынмас», - дип
язылган сүзләр тормышка ашсын өчен булды. 37 Изге Язманың башка бер
урынында: «Алар чәнчегән Затка карарлар», - дип тә язылган.

## Гайсәне кабергә салу

38 Шуннан соң, яһүдләрдән куркып, Гайсәнең шәкерте булуын яшереп йөргән
ариматейле Йосыф Пилаттан Гайсәнең гәүдәсен алырга рөхсәт сорады. Пилат
рөхсәт бирде һәм ул Гайсәнең гәүдәсен хачтан барып алды. 39 Элегрәк төнлә
Гайсә янында булган Никәдим дә килде һәм үзе белән йөз кадакка якын мирра
белән алоэ кушып ясалган хушбуй китерде. 40 Шулай итеп, алар, Гайсәнең
гәүдәсен алып, яһүдләрнең күмү йоласы буенча, Аны хушбуй сөртелгән кәфенгә
урадылар. 41 Гайсә хачка кадакланган җирдә бер бакча, ә бакчада әле һичкем
салынмаган яңа кабер бар иде. 42 Яһүдләрнең бәйрәмгә хәзерлек күрә торган
җомга көне булганлыктан, Гайсәне шунда салдылар, ченки кабер якын иде.

## Гайсәнең терелеп торуы

20:1 Магдалалы Мәрьям атнаның беренче көнендә иртән иртүк, әле караңгы
вакытта ук, кабер куышы янына килде һәм кабер алдыннан ташның читкә алып
ташланганын күрде. 2 Ул шунда ук Симон Питер һәм Гайсәнең теге яраткан
шәкерте янына йөгереп барып, аларга: - Ходайны кабердән алып киткәннәр. Кая
куйганнарын белмибез, - диде. 3 Питер белән әлеге шәкерт шундук кабер янына
киттеләр. 4 Алар икесе дә йөгерделәр, әмма теге шәкерт Питергә караганда
җәһәтрәк йөгергәнгә күрә кабер янына алданрак барып җитте. 5 Иелеп карагач,
анда яткан кәфенне күрде, ләкин кабер эченә кермәде. 6 Аның артыннан ук
Симон Питер килеп җитте. Ул, кабер эченә кереп, анда яткан кәфенне 7 һәм Аның
башына чорналган яулыкны күрде, әмма яулык кәфен белән бергә түгел, бәлки,
чорнап куелганча, үз урынында ята иде. 8 Шуннан соң кабер янына алданрак
килгән әлеге шәкерт тә эчкә керде һәм күреп иман китерде. 9 Алар Изге Язмада
Гайсәнең үлгән җиреннән терелеп торачагы турында язылганны әле аңламыйлар

иде. 10 Шуннан соң шәкертләр тагын өйләренә таралыштылар. 11 Мәрьям исә
кабер янында елап басып калды. Елыйелый иелеп кабер эченә карады һәм 12
анда актан киенгән ике фәрештәне күрде. Аларның берсе Гайсә гәүдәсе яткан
урынның баш очында, икенчесе аяк очында утыра иде. 13 Алар аңардан: - Хатын!
Нигә елыйсың? - дип сорадылар. - Минем Ходаемны алып киткәннәр. Аны кая
куйганнарын белмим, - диде ул. 14 Шулай дигәннән соң артына борылып карады
һәм анда басып торган Гайсәне күрде, әмма Аның Гайсә икәнен танымады. 15
Гайсә аңа: - Сеңелем! Нигә елыйсың? Кемне эзлисең? - дип әйтте. Мәрьям, Аны
бакчачы дип уйлап: - Әфәндем! Син Аны чыгарып куйган булсаң, кая куйганыңны
әйт, мин Аны алып китәрмен, - диде. 16 Гайсә аңа: - Мәрьям! - диде. Ә ул
әйләнеп карап, яһүдчә: - Раббуни! (ягъни Остаз) - дип әйтте. 17 Гайсә аңа: - Миңа
кагылма, чөнки Мин әле Атам янына күтәрелмәдем. Кардәшләрем янына кайтып
әйт: «Мин Үземнең Атам һәм сезнең Атагыз янына, Үземнең Аллам һәм сезнең
Аллагыз янына күтәреләм», - диде. 18 Магдалалы Мәрьям шәкертләр янына
килеп: - Мин Ходайны күрдем, - диде һәм аларга Гайсәнең әйткән сүзләрен
сөйләп бирде. 19 Шәкертләре шул ук көнне кич белән, яһүдләрдән куркып, йорт
ишекләрен бикләп җыелып утырганда, Гайсә килеп керде һәм, уртага басып,
аларга: - Иминлек сезгә! - диде. 20 Шулай дигәннән соң, Ул аларга кулларын һәм
кабыргаларын күрсәтте. Шәкертләр Ходайны күргәннәренә бик куандылар. 21
Гайсә аларга тагын: - Иминлек сезгә! Атам Мине җибәргән кебек, Мин дә сезне
җибәрәм, - дип әйтте. 22 Моны әйткәч, Ул сулышын аларга өреп: - Изге Рухны
кабул итегез. 23 Кемнең гөнаһларын кичерсәгез, шуныкы кичерелер; кемнекен
кичермәсәгез, аныкы кичерелмәс, - диде.

## Күрмичә иман китерүчеләр бәхетле!

24 Гайсә килгәндә уникенең берсе, Игезәк кушаматлы Тома, алар янында түгел
иде. 25 Башка шәкертләр аңа: - Без Ходайны күрдек! - диделәр. Ә ул аларга: -
Аның кулларындагы кадак яраларын күрмичә, кадак яраларына бармагымны,
кабыргаларына кулымны тидереп карамыйча, ышанмам, - дип әйтте. 26 Бер
атнадан соң Аның шәкертләре бер йортта тагын җыелып утырганда, Тома да алар
белән бергә иде. Гайсә ишекләр бикле килеш килеп керде һәм аларның уртасына
басып: - Иминлек сезгә! - диде. 27 Аннары Томага: - Бармагыңны монда куй һәм
кулларыма кара; кулыңны суз да кабыргаларыма тидер; шикләнүеңне туктат һәм
иман китер, - дип әйтте. 28 Тома Аңа җавап биреп: - Минем Ходаем һәм минем
Аллам! - диде. 29 Гайсә: - Син Мине күргәнгә күрә иман китердең. Күрмичә иман
китерүчеләр бәхетле! - дип әйтте. 30 Гайсә Үзенең шәкертләре алдында бу
китапта язылмаган башка бик күп могҗизалы галәмәтләр дә күрсәтте. 31 Болар
исә сез Гайсәнең Алла Улы, Мәсих булуына иман китерсен өчен һәм, иман
китереп, Аның исеме аркылы сезгә тормыш булсын өчен язылды.

## Гайсәнең шәкертләре белән очрашуы

21:1 Гайсә шушы хәлләрдән соң Тибериас диңгезе буенда шәкертләренә янә
күренде. Аның күренүе болай булды: 2 Анда Симон Питер, Игезәк кушаматлы
Тома, Галилеянең Кана шәһәреннән Натанаил, Зәбәйдәс уллары һәм Гайсәнең
тагын ике шәкерте бергә иделәр. 3 Симон Питер: - Балык тотарга барам, - дигәч,
калган шәкертләр аңа: - Без дә синең белән барабыз, - диделәр. Алар көймәгә
утырып, йөзеп киттеләр, әмма ул төнне һичнәрсә тота алмадылар. 4 Таң атканда
яр буенда Гайсә басып тора иде, әмма шәкертләре Аның Гайсә икәнен
танымадылар. 5 Гайсә аларга: - Егетләр! Сезнең ашарга берәр нәрсәгез бармы? -
диде. Алар Аңа: - Юк, - дип җавап бирделәр. 6 Ул аларга: - Ятьмәне көймәнең уң
ягына салыгыз, тотарсыз, - диде. Алар шулай иттеләр һәм эләккән балыкның
күплегеннән ятьмәне тартып чыгара алмадылар. 7 Шунда Гайсәнең яраткан
шәкерте Питергә: - Бу - Ходай, - диде. «Бу - Ходай», - дигәнне ишеткәч, Симон
Питер, өс киемен киеп, (ул чишенгән иде) диңгезгә сикерде. 8 Э ярдан йөз кырык
аршын чамасы гына ераклыкта булган башка шәкертләр, көймә белән килеп,
балык белән тулы ятьмәне сөйрәп ярга алып чыктылар. 9 Ярга чыккач, алар
икмәкне һәм учакта яткан балыкны күрделәр. 10 Гайсә аларга: - Тоткан
балыкларыгызның беразын монда алып килегез, - диде. 11 Симон Питер зур
балыклар белән тулы ятьмәне өстерәп җиргә чыгарды. Анда йөз илле өч балык
бар иде. Шул чаклы күп балык булуына да карамастан ятьмә ертылмады. 12
Гайсә аларга: - Ашарга килегез, - диде. Шәкертләрнең берсе дә Аннан: «Син
кем?» - дип сорарга батырчылык итмәде, чөнки алар Аның Ходай икәнен
белделәр. 13 Гайсә якынрак килеп икмәкне алды һәм аларга өләште, шулай ук
балыкны да алып аларга бирде. 14 Бу инде Гайсәнең үлеп терелгәннән соң
шәкертләренә өченче тапкыр күренүе иде. 15 Гайсә, ашаганнан соң, Симон
Питердән: - Юныс улы Симон! Син Мине башка шәкертләремә караганда күбрәк
яратасыңмы? - дип сорады. Питер Аңа: - Әйе, Раббым! Син Минем яратуымны
беләсең, - дип җавап бирде. Гайсә аңа: - Минем бәрәннәремне көт, - диде. 16
Гайсә икенче мәртәбә: Юныс улы Симон! Син Мине яратасыңмы? - дип сорады.
Питер Аңа: - Әйе, Раббым! Син Минем яратуымны беләсең, - дип җавап бирде. -
Минем сарыкларыма көтүче бул, - диде. 17 Өченче мәртәбә Ул аннан: - Юныс
улы Симон! Син Мине яратасыңмы? - дип сорады. Питер, Аның: «Син Мине
яратасыңмы?» - дип, өченче мәртәбә соравына көенеп, Аңа: - Раббым! Син
бөтенесен беләсең. Син Минем яратуымны да беләсең, - дип җавап бирде. Гайсә
аңа: - Минем сарыкларымны көт, - диде. 18 Сиңа чын дөресен әйтәм: син яшь
чакта үзеңне-үзең билбаулап, теләгән җиреңә бара идең. Э картайгач,
кулларыңны сузарсың, һәм башка берәү, сине билбаулап, теләмәгән җиреңә
алып барыр. 19 Ул бу сүзләрне Питернең нинди үлем белән Алланы данлаячагын
бедцереп әйтте. Шуннан соң Гайсә аңа: - Минем артымнан бар, - диде. 20 Шул
вакыт Питер, артына әйләнеп карагач, артларыннан Гайсәнең яраткан шәкертенең
килүен күрде. Бу - кичке аш вакытында Гайсәнең күкрәгенә терәлеп диярлек
утырган, «Раббым! Сиңа кем хыянәт итәчәк?» дип сораган шәкерт иде. 21 Питер,
аны күргәч, Гайсәдән: - Раббым! Аның белән нәрсә булачак? - дип сорады. 22
Гайсә аңа: - Мин килгәнгә кадәр аның яшәвен теләсәм дә, анда синең ни эшең

бар? Син Минем артымнан бар, - диде. 23 Шуңа күрә кардәшләр арасында «ул шәкерт үлмәячәк», дигән сүз таралды. Эмма Гайсә аңа «үлмәячәк» димәде, бәлки: «Мин килгәнгә кадәр аның яшәвен теләсәм дә, анда синең ни эшең бар?» - диде. 24 Бу вакыйгаларга шаһәдәт биреп, бу сүзләрне язган шәкерт - шул шәкерт була. Без аның шаһәдәтенең хак икәнен беләбез. 25 Гайсә болардан башка да күп эшләр башкарды. Аларның һәммәсе турында да язылса, язылган китаплар дөньяга сыймас иде дип уйлыйм.